# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

4/ 2023

***Һәр халыкның үз орнаменты, үз мәдәният коды бар***



ПРЕЗИДЕНТСКИЙ
ФОНД КУЛЬТУРНЫХ
ИНИЦИАТИВ

# «Россия» күргәзмәсендә Татарстан чыршысы балкый

Быелның ноябрь ахырында Мәскәүнең Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә (ВДНХ) «Россия» Халыкара күргәзмә-форумы ачылды. «Россия» күргәзмә-форумы кысаларында «Россия чыршылары» проекты да тормышка ашырыла. Биредә илебезнең 89 төбәге чыршысын күрергә мөмкин. Шунысы кызык, барлык чыршылар да халык һөнәрчелеге эшләнмәләре белән бизәлгән.

23 ноябрь көнне биредә «Татарстан чыршысын» да тәкъдим иттеләр. Чарада Татарстан мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Әдһәмова, шулай ук «Татарстанның мәдәни ресурс үзәге» хезмәткәрләре – директор урынбасары Эльвина Якупова, Ренат Әхмәтханов, Нияз Кәримуллин катнашты.



Луиза Киселёва фоторәсемнәре

# «Без дус-тату яшәгәндә, бердәм булганда гына көчле»



– Сезне чын күңелдән Халыклар бердәмлеге көне белән котлыйм. Бу бәйрәм зур илебезнең халыкларының бердәмлеге күрсәткече булып тора. Уртак җиңүләребез һәм казанышларыбыз символы. Без дус-тату яшәгәндә, бердәм булганда гына көчле.

Бу – илгә тышкы басым ясалган заманда аеруча мөһим. Россиягә дус булмаган илләр җәмгыятебезне таркатырга, кешеләрне милли һәм дини билгеләр буенча аерырга тели. Илнең суверенитетын саклап калуның төп шарты – төрле милләт вәкилләре арасында дустанә мөнәсәбәтләрне югалтмау. Бу максаттан республикада төрле дәүләт программалары чынга ашырыла. Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында да зур эш башкарыла. Татарстанда 13 милләтләр дуслыгы йорты һәм 100гә якын мәдәни үзәк эшли. Алар халыклар дуслыгын ныгытуга зур өлеш кертә. Барыгызны да бәйрәм белән! Бергә булыйк, бердәм булыйк!

**Рөстәм Миңнеханов,**
*Татарстан Республикасы Рәисе*

**(Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын йомгаклау уңаеннан «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә уздырылган чарадагы чыгышыннан)**




Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# ЭЧТӘЛЕК

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ





4 **Белоруссиядә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре**

6 **Чечен Республикасында Татарстан мәдәнияте көннәре узды**

8 **Татарстан мәдәнияте көннәре – Төркмәнстанда**

10 **Күңел бизәкләре – картада**

12 **Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына йомгак ясалды**


## ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...




14 Р. Сәүбәнова **Гүзәллек туган йорт**

19 А. Әскәрова **Гади агачтан могҗиза тудыручы**


## ӘДӘБИ МИРАС




22 Л. Мөхәммәтҗанова **Татар халкының тарихи җырлары**


## МИФОЛОГИК МИРАС


28 Г. Гыйльманов **Кыяфәтнамә – мифмы, чынбарлыкмы?**



Түгәрәк уен

№ 4 (50) / 2023


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*

*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы
Мәдәнният министрлыгы каршындагы
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге



Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов



Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 07.12.2023
Чыгу көне: 20.12.2023
Заказ: 067813 Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78



Кулъязмаларга бәя бирелми,
алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.


**Тышлыкта: Татарстан чыршысын бизәүдә кулланылган уенчыклар «Ишморат» студиясендә ясалды.**


© «Түгәрәк уен», 2023

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ




34 Г. Мусина
**Каз өмәсе**

36 Р. Зарипова
**«Каурый» бәйрәме (Фольклор күренеш)**


## МИЛЛИ УЕННАР




40 Л. Габитова
**«Ашык» уены**


## БЕЗГӘ ЯЗАЛАР




44 Р. Закирова,
Г. Сөнгатуллина
**«Чишмәләребез ни хәлдә?»**

48 Ф. Нигъмәтҗанов
**Милли ризык – өстәл күрке**


## БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ





50 Т. Галиуллин
**Мөнәҗәтләр – җан авазы**


## БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...




54 **Төмәнәк талантлары**

57 **Ява карлар**
(Җыр)


## ӨЙ КҮРКЕ – АШ




58 **Борчак чумары**


## ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ


62 **Бергәләп бизибез!**





# Белоруссиядә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре

**2022 елның августында Белоруссия Республикасы мәдәнияте көннәре Мәскәү, Йошкар-Ола һәм Казан шәһәрләрендә барган иде. Эстафетаны үз кулларына алып, быелның 11-14 сентябрь көннәрендә Белоруссиядә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре узды.**

Әлеге чарада Татарстанның алдынгы һөнәрчеләре эшләреннән торган декоратив һәм гамәли сәнгать күргәзмәләре эшләде. «Халык һөнәрләрен үстерү өчен шартлар тудыру» түгәрәк өстәле артында экспертлар бу мәсьәләдә тәҗрибә уртаклашты.

Татарстан сәнгать осталары концертында республиканың әйдәп баручы башкаручылары, Татарстанның халык артисты,

республиканың атказанган сәнгать эшлеклесе Миләүшә Тәминдарова җитәкчелегендәге Татарстан Дәүләт камера хоры, Татарстан Дәүләт фольклор музыкасы ансамбле, «Казан нуры» халык уен кораллары оркестры катнашты.

Мәдәният көннәре кысаларында Татарстан Милли музее белән Белоруссия Милли тарихи музее арасында хезмәттәшлек турында килешүләр имзаланды. Белоруссия Милли китапханәсенә Татарстан тарихы, мәдәнияте һәм сәнгате турында китаплар бүләк ителде.

Быел Татарстан Милли музеенда традицион белорус мәдәнияте турында «Белоруссиянең тере мирасы» дигән зур күргәзмә дә ачылган иде. Залларда белорус халкы борынгыдан дан тоткан туку һәм чигү, мичкә ясау һәм чүлмәкчелек эше, агачтан уеп ясау һәм салам үрү һөнәрчелек әйберләре тәкъдим ителде. Күргәзмә 17 сентябрьгә – Белоруссиядә билгеләп үтелүче Халыклар бердәмлеге көненә кадәр эшләде.









# Чечен Республикасында Татарстан мәдәнияте көннәре узды

**Быелның 26-28 сентябрендә Чечен Республикасында Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре узды. Аның рәсми ачылышы Грозныйның М.Ю. Лермонтов исемендәге Дәүләт рус драма театрында булды. Тантанада Чечен Республикасы Хөкүмәте Рәисе Муса Дадаев һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов катнашты, ул Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның сәламләү хатын укыды.**





«Әле күптән түгел генә без Казанда Чечняның танылган мәдәният һәм сәнгать эшлекләренең чыгышларын карап ләззәтләнгән идек, ә бүген Татарстан сәхнә осталары сезгә җавап визиты белән килде. Музыка, җыр, биюләр – һәр халыкның җаны, һәм без кадерле туганнарыбыз белән иң кадерле һәм изге әйберләр – рухи байлык, матур гореф-гадәтләр һәм йолалар белән бүлешәбез», – диелә Татарстан Республикасы Рәисенең сәламләү хатында.

Тамашачылар игътибарына Габдулла Тукай исемендәге Әтнә Татар дәүләт драма театрының Әхмәт Фәйзинең «Акчарлаклар»






әсәре буенча сәхнәләштерелгән спектакле дә тәкъдим ителде.

Чечня Республикасында Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре параллель рәвештә Урус-Мартанның У. Димаев исемендәге Мәдәният сараенда да ачылды. Биредә Татарстанның халык артисты Миләүшә Тәминдарова җитәкчелегендәге Татарстан Дәүләт камера хоры чыгыш ясады.

Татарстан мәдәнияте көннәре уңаеннан оештырылган чаралар барышында Чечня Милли китапханәсендә ике республиканың халык сәнгать һөнәрчелеге дизайнерлары һәм осталары катнашында түгәрәк өстәл узды. Дагун Омаев исемендәге Тантаналар сараенда кинематографистлар очрашуы булды. Татарстанның «Мулла» һәм «Тарлан» фильмнары күрсәтелде. Чечня Милли китапханәсендә «Китап – мәдәниятләр киңлегендә» китап күргәзмәсен ачу Татарстанның ике картинасын («Ибн Фадлан», «Без – 41нче ел балалары») күрсәтү белән дәвам итте. Китапханәгә Татарстан тарихы, мәдәнияте һәм сәнгатенә багышланган китаплар бүләк ителде.

Татарстан мәдәнияте көннәре А. Шахбулатов исемендәге Чечня дәүләт филармониясендә Татарстан Республикасы сәнгать осталарының – Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле катнашында гала-концерты белән тәгәлләнде.







# Татарстан мәдәнияте көннәре – Төркмәнстанда



**Быелның 17-19 октябрендә Төркмәнстанда Татарстан мәдәнияте көннәре булып узды. Төркмәнстан Дәүләт мәдәни үзәгенең Мукамов сараенда узган ачылу тантанасында Төркмәнстан мәдәният министры урынбасары Корбан Мурадалиев һәм Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова катнашты.**

Биредә декоратив-гамәли сәнгать һәм сувенир продукциясе эшләнмәләре күргәзмәсе, Татарстанның халык сәнгать кәсепләре осталарының эксклюзив авторлык эшләре күрсәтелде, Татарстанның ЮНЕСКО объектлары фотокүргәзмәсе эшләде һәм Татарстан сәнгать осталары концерт куйды.

18 октябрьдә Мары шәһәрендә Мары вилаятенең Кемине исемендәге Дәүләт драма театрында тамашачыларга Татарстан сәнгать осталары концерты тәкъдим ителде. Шул ук көнне Ашхабадта Бөек Сәпәрмурат Төркмәнбашы исемендәге Төркмәнстанның сынлы сәнгать музеенда «Халык сәнгать кәсепләрен һәм һөнәрләрен саклау, торгызу һәм үстерү» темасына түгәрәк өстәл узды.

Татарстан киносы көннәре кысаларында «Ашхабад» кинотеатрында «Ибн Фадлан», «Тарлан», «Исәнмесез» татар кинофильмнары күрсәтелде.

Татарстан мәдәнияте көннәре Төркмәнстан Дәүләт мәдәни үзәгенең Мукамов сараенда Татарстан һәм Төркмәнстан мәдәният һәм сәнгать осталарының дуслык концерты белән тәмамланды.







# Күңел бизәкләре – картада

**«Татарстан Республикасының чигелгән картасы» проекты Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов карары белән игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан оештырылды. Проектның максатлары – республикадагы күпмилләтле халыкның бердәмлеген ныгыту, иҗади үсеш һәм декоратив-гамәли сәнгать белән шөгыльләнүче осталарны берләштерү, милли чигү традицияләрен саклау.**

Әлеге акциянең учредительләре – Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Советы» ассоциациясе.

Проектны турыдан-туры оештыручы – «Татарстанның мәдәни ресурс үзәге» оешмасы.

Проектның партнерлары – Тарихи һәм мәдәни мирасны саклауга булышлык итүче «Татнефть-Наследие» үзәге, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗәни исемендәге Тарих институты, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, Казанның халык һөнәрчелеге техникумы, Татарстанның Милли музее, «БЮРО БАНУ» остаханәсе.

«Татарстан Республикасының чигелгән картасы» проекты быелның февраль-июнь айларында үтте. Татарстанның 43 районы һәм ике шәһәр округыннан булган 23 яшьтән алып 70 яшькә кадәрге 52 чигү остасы, рәссамнар ясаган эскизлар буенча, үз төбәкләренең картасын чикте. Чиккәндә осталар мәдәни-тарихи һәм географик үзенчәлекләрне күрсәтергә тырыштылар, шул исәптән тарихи урыннарны һәм үз районнарын данлаган шәхесләрне дә исәпкә алдылар. Ахырда барлык кисәкләр дә бергә тоташтырылып, Татарстанның йөзе тасвирланган тулы карта ясалды.

Республиканың проект кысаларында чигелгән 2 метрга 3 метрлы картасы июнь башында Чувашия Республикасына китте. Анда ул «Чиккән Россия» Бөтенроссия фестивалендә катнашты.

Әлеге картаны быелның 15-23 июль көннәрендә Казанда һәм Болгарда узган «Яңарыш: Эпосның заманча укылышы» фестивалендә һәм 3 ноябрьдә Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә узган чарада да күрергә мөмкин иде.

Республиканың 3 метрга 5 метрны тәшкил иткән картасы да кечерәк карта принципларында эшләнелде. Зур карта Татарстанда калачак һәм республикада уза торган төрле чараларда, бәйрәмнәрдә, шулай ук Россия төбәкләрендәге күргәзмә-ярминкәләрдә катнашып, республикабызны, аның мәдәниятен, милли йөзен тәкъдим итәчәк.

***Ленар Хәкимҗанов,***
*Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары:*

***«Безнең өчен «Татарстанның чигелгән картасы» проекты – мәдәни тормышның кызыклы этабы, анда без бергәләп эшләп, күп нәрсәгә өйрәндек, шулай ук бергәләп тарихка һәм мәдәниятка чумдык. Татарстанның һәр районы уникаль һәм республика үсешенә үз өлешен кертә. Безнең нинди байлыгыбыз барлыгын һәр татарстанлы белсен өчен әлеге картаны кешеләргә күрсәтергә кирәк».***






*● Картада барлык 45 фрагмент та борынгы чигеш технологиясен кулланып эшләнгән: биек/тәбәнәк тамбур, тоташтан чигү техникасы һәм келәм чигеше.*

*● Карта сурәтләренә колоритлы табигать төсмерләрендә башкарылган традицион үсемлекләр һәм геометрик бизәкләр кертелгән. Осталар республика территориясендә яшәүче төп халык: татар, рус, чуваш, мари, удмурт, мордваларның милли байлыгын күрсәтергә тырышкан.*

*● Республикабызның төп су байлыгы – Идел һәм Чулман елгалары сурәтләре картаның композицион элементы булып тора.*

*● Татарстан Республикасының башкаласы – Казан территориясе яшел фонда алтынлы чигеш технологиясе кулланып башкарылган. Картада татар риваятьләрендәге уйдырма җан иясе – Зилант аждаһа сурәтләнгән. Зилант шәһәр гербында бик борынгы заманнардан ук урын алган. Башкала картасында шулай ук Казан Кремленең тарихи һәм архитектура һәйкәлләре – Благовещенск соборы, Сөембикә манарасы, Кол Шәриф мәчете һәм шәһәр халкының һәм кунакларның яраткан урыны – «Казан» гаилә үзәге (халык теленә ул «Чаша» – «Касә» исеме белән кереп калды) сурәтләнгән.*

*● Картаның «Татарстан Республикасы» дигән исеме Дәүләт флагы төсләрендә чигелгән. Һәр төсмер символик мәгънәгә ия. Яшел төс – яшәеш, үсеш, яңа казанышларны; ак төс – иминлек, ниятләрнең чисталыгын; кызыл төс яшәү көчен, тормыш егәрлеген гәүдәләндерә.*

*● Картаның уң яктагы өске почмагында Татарстан Республикасының 2023 елгы – Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы логотибы сурәтләнгән. Янәшәдә Россия һәм Татарстан герблары чигелгән. Астагы сул як почмакта «Татарстан Республикасының чигелгән картасы» акциясенең рәсми партнерлары логотиплары сурәтләнгән.*

*● Картаның каймасы табигатьнең уянуын һәм Татарстанның яңа көч алуын символик гәүдәләндерүче татар халык бизәкләрендә башкарылган.*

*● Картаның барлык административ-территориаль бүленеш масштаблары Татарстан Республикасы табигый-географик картасының пропорциональ версиясе булып тора.*

# Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына йомгак ясалды




**Быелның 3 ноябрендә, Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан, «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына йомгак ясалды.**

Көн дәвамында «Казан Экспо» үзәгендә Татарстанда яшәүче халыкларга, аларның Сабан туе, Уяв, Питрау, Иван Купала кебек бәйрәмнәргә багышланган экспозицияләр, күргәзмәләр, фәнни секцияләр, мастер-класслар эшләде.

Күргәзмә үзәгенең беренче катында районнардагы җирле осталар иҗат иткән, милли орнаментлар белән бизәлгән Татарстанның чигүле картасы тәкъдим ителде. Шулай ук чигүле әйберләр турында күбрәк белергә теләүчеләр өчен бизәкле сөлгеләр күргәзмәсе дә оештырылган иде.

– Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан Республика күләмендә 500дән артык зур чара уздырылды. Быел милли чараларга аеруча тирән мәгънә салынды. Гореф-гадәтләр, традицияләр – динебезнең, милләтебезнең нигезе дип санала. Дөрестән дә, бу ел безнең өчен бик мөһим иде, – диде Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин.

Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында нәтиҗәле



эшләүчеләрне бүләкләү, «Татарстанның мәдәни башкаласы» конкурсына йомгак ясау Илһам Шакиров исемендәге концертлар залында дәвам итте. Әлеге чарада Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

«Татарстанның мәдәни башкаласы» бәйгесендә 45 район катнашты. Һәр район күргәзмәләр, туристик маршрутлар, милли ашлар үзенчәлекләре, халык сәнгате һәм һөнәрчелек, иҗат төркемнәре чыгышлары аша культураны тәкъдим итте.

Гран-при һәм «Татарстанның мәдәни башкаласы» исеменә Арча районы лаек булды.

1 урында: Әтнә, Актаныш, Алабуга;

2 урында: Теләче, Аксубай, Кукмара;

3 урында: Чүпрәле, Саба, Бөгелмә районнары.







Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# ГҮЗӘЛЛЕК ТУГАН ЙОРТ

*Рашания СӘУБӘНОВА,*
*Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы директоры*

**Быел Татарстанның милли брендын иҗат итүчеләрне әзерли торган эксклюзив уку йорты – Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы өчен юбилей елы: 40 нчы техник һөнәр училищесы ачылуга – 60 ел. Бүгенге «Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы» дәүләт һөнәри белем бирү учреждениесе – Ресурс үзәгенең нигезе мәгариф реформалары кичергән, 34 нче һөнәри лицей белән кушылып, яңа юнәлешләр һәм мәгълүмати агымнар өстәлгән шушы уку йортына барып тоташа.**

Уку йортының миссиясе – халык сәнгать һөнәрчелеген һәм кәсепчелеген өйрәнү, традицияләрне яңарту, татар халкының тарихи һәм мәдәни мирасын саклау һәм үстерү. Биредә белем алган яшьләребезгә халкыбызның онытыла барган һөнәрләрен торгызу, кул эшләренең матурлыгын җиткерү бурычы йөкләнә. Моңа ирешү өчен укыту инфраструктурасы заман таләпләренә туры китереп яңартыла, сыйфатлы белем алу өчен шартлар тудырыла.

Иҗат һәм яшьлек энтузиазмы белән тулы уку йорты диварлары эчендә кул эшләренең нинди генә төрләре уйлап табылмый да, нинди генә үзенчәлекле әйберләр иҗат ителми! Биредә үзләре дә башкаларның остазы булачак шәхесләр әзерләнә.

**● Халыкның тарихи һәм мәдәни хәтерен саклау, традицияләрне яңарту һәм үстерү Татарстанда өстенлекле юнәлеш булып кала бирә. 2010 елда республикада «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар һәм Зөя утрау-шәһәрлеге» комплекслы проекты кабул ителде. Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев тарафыннан «Татарстан Республикасының тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен торгызу республика фондын булдыру турында» Указга кул куелды. Указда беренче чиратта яңартылырга тиешле объектлар итеп, Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы һәм «Зөя утрау-шәһәрчеге» Дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музее танылды. Моңа бәйле рәвештә техникум базасында борынгы зәркәнчеләр мирасын өйрәнү һәм Идел буе Болгар дәүләте белән Казан татарларының зәркән эшләнмәләре ясау традицияләрен яңарту буенча фәнни-тикшеренү лабораториясе ачылды. Зәркәнчелек сәнгате үсешенә Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиев нык ярдәм итә. Хәзер республика шушы ярдәмнең нәтиҗәсен күрә: зәркәнчелек осталыгына өйрәтү – техникумның әһәмиятле юнәлешләреннән берсе.**

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов уку йортына һәрьяклап булыша, Татарстанның милли брендын булдыру традицияләрен дәвам итәчәк яшь зәркән осталарының уңышлары белән кызыксынып тора. 2018 елның мартында Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумына килгәч, ул WorldSkills Russia конкурсы биремнәрен үтәү буенча әзерлек эшләре белән танышып чыкты, техникум укучыларының эшчәнлеген югары бәяләде.



**Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы студентлары иҗаты**

**Техникум студентлары WorldSkills Russia (һөнәрчеләр) хәрәкәтенә 2013 елдан кушылып китте. 2017 елда «Зәркәнчелек эше» белән бер рәттән ярышлар өчен «Зәркән кашларын кырлау» яңа компетенциясе дә кертелде. 2020 елда 2020/2021 еллардагы чемпионат циклы кысаларында техникумга «Керамика һөнәре», «Керамика һөнәре – юниорлар», «Ювелир эше – юниорлар» кебек яңа компетенцияләр, 2022 елда «Агачны сәнгати бизәү» компетенциясе дә өстәлде. Чемпионатның төрле этапларында студентлар 27 алтын, 35 көмеш, 30 бронза медаль һәм профессиональлек өчен 3 медальон яулады.**


Раушания Кыяметдин кызы Сәүбәнова

Конкурсантларның уңышлы чыгышын тәэмин итү максатыннан техникум базасында «Зәркәнчелек эше», «Зәркән кашларын кырлау», «Керамика һөнәре» компетенцияләре буенча махсуслашкан сертификацияле үзәкләр оештырыла. Мәйданчыкларда «Профессионаллар», «Абилимпикс» чемпионатларын һәм Демонстрацион имтиханнар үткәрү буенча сертификацияле экспертлар эшли.

**2021 елның декабрендә Татарстан Республикасында ишетү сәләте зарарланган кешеләр өчен беренче тапкыр DeafSkills һөнәри осталык милли чемпионаты узды. Ул «Россия Федерациясендә ишетү сәләте бозылган яшьләр өчен иҗтимагый процессларда катнашу, бәйсезлек һәм эшкә урнашу» социаль проекты кысаларында, «Бөтенроссия ишетмәүчеләр» гомумроссия инвалидлар иҗтимагый оешмасы тарафыннан, «Уңыш» ишетү сәләте бозылган яшьләр оешмасы» регионара инвалидлар иҗтимагый оешмасы белән берлектә, Берләшкән Милләтләр Оешмасының Демократик Фонды грантына оештырылган иде. Ярышлар Техникум базасында «Декоратив сәнгать» һәм «Зәркән эше» компетенцияләре буенча үтте.**

2010 елдан бүгенге көнгә кадәр Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумын Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, педагогика фәннәре кандидаты, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты доценты Раушания Кыяметдин кызы Сәүбәнова җитәкли. Ул исемнәре уку йорты тарихына язылган җитәкчеләр –1963-1985 елларда 40нчы ПТУны җитәкләгән Заһит Абдрахман улы Патеев, 1985-1992 елларда училище директоры булган Җәвит Нургали улы Закиров, 1992-2010 елларда уку йортын ныклы кулларына алган Әлфия Мөхәммәт кызы Нуриева, 1975-1999 елларда 34нче ГПТУны җитәкләгән Лидия Васильевна Плошкина, 2000-2009 елларда 34нче һөнәри лицей директоры булган Ираида Ивановна Аниканова эшен лаеклы дәвам итә.

Аның килүе белән мәгариф учреждениесенең яңа тарихы языла башлый. 2010-2013 елларда мәгариф һәм тәрбия процесслары модернизацияләнә, учреждение аккредитация уза һәм яңа федераль дәүләт мәгариф стандартларына күчә, яңа белгечлекләр ачыла, мультимедиа, мәгълүмати технологияләр кертелә,





сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә һөнәри белем алу өчен уңайлыклар тудыру максатыннан, «Уңайлы мохит» программасы кысаларында, махсус уку урыннары булдырыла. 2018 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән учреждениенең статусы үзгәртелә: техникум дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә әверелә.

Техникумның интеллектуаль фонды уникаль – талантлы мастерлар һәм педагоглар, хезмәт ветераннары. Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы укытучыларының педагогик эшчәнлеге дәүләт югарылыгында билгеләп үтелүе гаҗәп түгел. Педагогларның белеме һәм осталыгы гомуми нәтиҗәгә төбәлүе осталарның уникаль иҗат җимешләре булып җитешә.

Хәзер Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы һөнәрче осталар әзерләүче зур ресурслар үзәген тәшкил итә. Инновацион мәгариф технологияләрен кертү эше яхшы оештырылган. Укучыларның заманча җиһазлар белән танышу, үзләре укыган тармак яңалыкларын белеп тору мөмкинлеге бар, алар производствога алдынгы белемнәр белән беррәттән ата-бабадан калган технологияләрне дә белеп килә, заманча цифрлы җиһазлар белән дә эш итә ала.

2019 елдан башлап, хәзергәчә, техникумда «һәр бала уңышы» федераль программасы кысаларында «Киләчәккә билет» проекты тормышка ашырыла. Әлеге проект балаларны мәктәп яшеннән үк кызыклы һөнәрләр белән таныштыруга юнәлтелгән, ул Россия Федерациясенең Гуманитар проектлар фонды кысаларында уздырыла. Профориентация максатларында һәм халык һөнәрчелеген популярлаштыру өчен 2021 елның октябреннән бирле, «Пушкин картасы» проекты ярдәмендә, остазлар балалар һәм үсмерләр өчен зәркәнчелек эше, чигү, керамика, сынлы сәнгать, рәсем, агачны уеп ясау һәм башкалар буенча осталык дәресләре уздыра.

- **Студентлар инициативасы белән техникумда «Яшь вакыт» дизайн-студиясе оешты. Дизайн-студиядә шөгыльләнү студентларга дәресләрдә алган белемнәрен чарларга гына түгел, архитектура, дизайн һәм IT-технологияләр тармагында үзара тәҗрибә уртаклашырга мөмкинлек бирә, һөнәрнең техник үзенчәлекләрен аңларга, дизайн-портфолио ясарга өйрәтә, шулай ук, «График дизайн» компетенциясе буенча «Профессионаллар» чемпионатында катнашу өчен әзерли. 2022 елның мартында «Яшь вакыт» дизайн-студиясе Мәдәни инициативалар Президент фонды грантына ия булды.**

- **2012 елдан бирле техникум эшләнмәләре «Татарстан Республикасының 100 иң яхшы товары һәм хезмәте» конкурсы дипломнары, «РФ һәм ТРда иң яхшы товарлар һәм хезмәтләр» билгесе белән бүләкләнеп килә. Көмештән һәм фирүзәдән скань һәм эмаль кушып ясалган татар милли алкалары «Новинка» Бөтенроссия конкурсы дипломы белән бүләкләнде.**



Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы Татарстан Республикасын төрле дәрәҗәдәге чараларда лаеклы тәкъдим итә, дөньяның төрле илләрендә оештырылган Сабантуйларда даими катнаша. Германия, Чехия, Франция һәм башка илләрдә яшәүче милләттәшләрнең бәяләмәләре студентларны татар милли рухы булган кабатланмас иҗат җимешләре тудырырга рухландыра.

**Техникум остазлары декоратив-гамәли төрләр буенча осталык дәресләре бирә, Федераль һәм Бөтенроссия масштабындагы чараларда – шул исәптән, Түбән Новгород, Томск, Новосибирск, Нижневартовск, Кемерово һәм башка шәһәрләрдә узган федераль дәрәҗәдәге Сабантуйларда ярминкә-күргәзмәләр оештыра.**

Бакуда узган Сабантуй мәйданчыгында да; татар авыллары эшмәкәрләренең XI Бөтенроссия җыены кысаларында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында узган пленар утырыш мәйданчыгында да; Бөтендөнья татар конгрессы «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасы белән берлектә оештырган Бөтендөнья татар хатын-кызлары корылтае мәйданчыгында да; «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum-2023» халыкара икътисади форумы мәйданчыгында да; журналистика һәм массмедиа өлкәсендә «Бәллүр каләм» XXVI конкурсы мәйданчыгында да; Бөтенроссия Спас ярминкәсендә дә; Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең август киңәшмәсенең пленар утырышы кысаларында да техникум күргәзмә-ярминкәләр белән катнашты.

**Техникумның нәфис эшләнмәләре республика күләмендәге һәм Бөтенроссия конкурсларында һәм фестивальләрдә катнашып призер һәм лауреат була. Техникум студентлары һәм укытучылары иҗат иткән әйберләр Россиянең генә түгел, АКШ, Бөекбритания, Швейцария, Австралия, Голландия, Португалия, Чехия, Венгрия, Болгария музейлары экспозицияләрен һәм шәхси коллекцияләрен бизи.**

Һөнәрчелекнең чигешле калфак-түбәтәйләр, милли киемнәр һәм каюлы читек-чүәкләр,




зәркән бизәнү әйберләре, керамика һәм агач әйберләр ясау кебек төрләре – татар мәдәниятенең хәзинәсе. Хәзер төрле эшләнмәләрдә фольклор мотивларын куллану модага керде һәм моңа сорау зур. Сәнәгатьтә күпләп җитештерелгән әйберләр кешене арытты, уникаль әйберләр популярлашты. Аерым бер иҗат юнәлеше булып торган хендмейд, ягъни, кул эшләре популярлыкның югары ноктасында. Уку йорты бүген костюмнар буенча рәссам, тегүче, чигүче, сәнгати бизәү эшләрен башкаручы, ювелир, керамикадан сәнгати әйберләр ясаучы, агачтан сәнгати әйберләр ясаучы, дизайн, декоратив-гамәли сәнгать һәм халык һөнәрчелеге квалификацияләре буенча эшчеләр һәм белгечләр әзерли.




Фоторәсемнәр Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы архивыннан

# ГАДИ АГАЧТАН МОГҖИЗА ТУДЫРУЧЫ

*Алсу ӘСКӘРОВА,*
*Әтнә үзәк китапханәсе җитәкчесе*

**Заманча технологияләр үсеш алган чор булуга карамастан, бүгенге көндә кулдан ясалган эшләнмәләр дә игътибар үзәгендә. Агач яисә башка чималдан эшләнгәнме, тегү-чигү, бәйләү кебек кул эшләреме ул – үзең тудырган матурлык һәрчак зәвыклы, кабатланмас була, ул һәркемнең игътибарын үзенә җәлеп итә, алар белән кызыксынучылар да көннән-көн арта. Чөнки адәм баласы табигать белән матурлыкка омтылып яши. Әлеге иҗат җимешләре останың рухи байлыгын, эчке дөньясын һәм тормышка карашын чагылдыра.**





Үз куллары белән гүзәллек тудыручы сәләтле, хөрмәткә лаеклы шәхесләр арабызда бик күп. Әтнә районы Түбән Шашы авылында яшәүче Татарстан һәм Россия Федерациясенең атказанган мал табибы, бүгенге көндә Күңгәр авылында имам вазыйфасын башкаручы, агачтан сыннар ясау остасы Мәхмүт Гаделҗан улы Хәкимҗанов – шундыйларның берсе. Ул гади генә агач ботагында да яки агач тамырында да матурлык, камиллек күрә. Гади агачтан да сәнгать әсәре тудыра. Аның кебекләр турында «алтын куллы», «кулыннан гөлләр тама» диләр. Дөньяның матурлыгын йөрәге белән тоеп яшәүче, хезмәт сөючән, ихлас күңелле, тыйнак, гап-гади авыл кешесе ул Мәхмүт абый Хәкимҗанов.

Мәхмүт Гаделҗан улы гомере буе иҗатка, туган ягына, аның кешеләренә, табигатенә гашыйк. Яшәүдән ямь, күңеленә якын шөгыль табып, кешеләргә игелек кылып яши. Тормышны яратуын ул агач сыннар, бизәкләр телендә җиткерә белә. Күңел җылысын салып эшләгәнгәме, шуңа да матур, зәвыклы һәм җанлы килеп чыга аның эшләре. Сыннарының һәркайсының үз холкы, үз төс-кыяфәте. Алардан җылы нур, яктылык бөркелә.

Мәхмүт абый җәй айларында урманда йөрергә ярата. Биредә ул сыннар ясау өчен материаллар эзли, агач ботаклары җыя, агач тамырлары казый, эшкә яраклы булганнарын алып кайтып, чистарта, эшкәртә. Сыннарны ул күбрәк көзен, яңгырлы көннәрдә башкара. «Күшәр урманында кәкре-бөкре агач тамырлары күп. Чимал җыйгач, композицияләрне ничек эшләргә икәнлеге турында уйланып, шуның белән хыялланып яши башлыйм. Илһам килүгә кулга корал алам. Агач белән эшләү үзе бер ләззәт, күңел тынычлыгы бит ул! Агач эше шундый мавыктыргыч, ясаган саен ясыйсы килә. Җирдә аунап яткан агач тамырын күрсәм дә, күңелемнән әллә нәрсәләр иҗат итә башлыйм. Сыннар ясау өчен күбрәк юкә агачы кулланам, чөнки аны эшкәртергә җайлы. Имән агачы нык, каты була. Аны юыну өчен коралның үткен булуы кирәк. Мин эшләгәндә пычак, балта, пычкы кебек гади генә кораллардан файдаланам», – дип, хис-кичерешләре, эш нечкәлекләре белән бүлешә оста.

Мондый зәвыклы сәнгать әсәрләре тудырырга ул үзлегеннән өйрәнә. 4нче сыйныфта укыганда ук кулына пычак алып, агачлар уеп, кырып, чокып, төрле образлар тудыра башлый. Беренче ясаган сыннары – дус малайлары белән уйнар өчен шахмат фигуралары була. Балачакта яраткан шөгылен ул бүгенге көндә дә ташламый, вакыты булган саен, кулына корал алып, агач уя. Ясаган сыннары күбәйгәч, аларны урнаштыру өчен, стеллажны да үзе корып куя.

Мәхмүт ага Тукай иҗатына гашыйк кеше, шуңа останың иҗат эшләрендә Тукай тематикасы күп. Останың күргәзмәсе белән танышканда үзеңне Тукайның әкияти дөньясында йөргән кебек хис итәсең. Нигә Тукай әсәрләрендәге образлар ясала дип уйлыйсыз? Очраклы түгел, чөнки Мәхмүт абыйның әтисе ягыннан нәсел җебе шагыйрьнең туган авылы Кушлавычка барып тоташа. Тукай әсәрләрен укып, Шүрәлеләр белән кызыксынып үскән малай шул ул. «Әле дә булса Тукайны яратып укыйм, күпме фикер салынган аның әсәрләренә... Милләтебезнең әкиятләре, риваятьләре, бәетләре күңелемне һәрчак җәлеп итә. Алар миңа иҗат итәргә илһам бирә», – ди Мәхмүт абый.

Мәхмүт аганың эшләрен һәркайда югары бәялиләр. Күп санлы мактау кәгазьләре, диплом-грамоталар шул хакта сөйли. Бүгенге көндә

дә ул тик ятмый, яраткан эше белән шөгыльләнә, гел хәрәкәттә, гел эзләнүдә. Районкүләм, республикакүләм фестивальләрдә, бәйгеләрдә, төрле очрашуларда, иҗади кичәләрдә катнаша. 2022 елда ул, өлкән яшьтәге агач ую осталары арасында үткәрелгән «Сынлы камиллек» республикакүләм фестиваль-конкурсында катнашып, тамашачылар призына ия булды һәм махсус кубок белән бүләкләнде.

Әтнә үзәк китапханәсендә дә останың кул эшләреннән торган шәхси күргәзмәсе эшләде һәм Мәхмүт абый белән күңелләргә җылылык, рухи азык бирүче эчкерсез очрашу кичәләре узды. Очрашуга килгән һәркем останың агач сыннарын сокланып карады. Ә Мәхмүт абый кызыксынучыларны үзенең эшләре белән таныштырды, нинди төр чимал белән эшләве, нинди кораллар куллануы турында тәфсилләп сөйләде, укучыларны кызыксындырган сорауларга да җавап бирде.

Мәхмүт абыйның иҗаты киң кырлы: ул архив материаллары өйрәнеп, тарихи мәгълүмат туплап, замандашлары истәлекләренә таянып, төрле елларда Күңгәрдә һәм тирә-юньдәге авыл мәчетләрендәге дин әһелләренең халыкка күрсәткән хезмәтләре турында «Күңгәр мәчетенең нуры» исемле китап та бастырып чыгарды. Биредә дин тыелган чорда авылдашларына рухи яктан үсәргә ярдәм иткән муллалар турында бик эчтәлекле мәгълүмат тупланган.

Бүгенге көндә Мәхмүт Гаделҗан улы тормыш иптәше Фаилә апа белән Әтнә районы Түбән Шашы авылында гомер кичерә. Фаилә ханым гомер буе мәктәптә укытучы булып эшләгән. Алар өч бала тәрбияләп үстергәннәр: олы уллары эшмәкәр, уртанчы уллары Әтнә шифаханәсендә табиб, кече кызлары баш хисапчы булып эшли. Лаеклы ялда булса да, Мәхмүт абый авылда имам вазыйфасын башкара, Казандагы Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсәдә белем ала.



Без Мәхмүт абыйга, гүзәллек тудыручы кулларына саулык, һәм алдагы көннәрендә дә иҗатында зур уңышлар телибез.




Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТАРИХИ ҖЫРЛАРЫ

*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институтының*
*баш фәнни хезмәткәре*



### ТАРИХИ ҖЫРЛАР МӨСТӘКЫЙЛЬ ЖАНРМЫ?

Фольклористикада халыкның үткән тарихындагы аерым социаль-тарихи вакыйгаларга, күренекле шәхесләргә һәм билгесез геройларга багышланган әсәрләрне тарихи җырлар төркеменә кертәләр. Кагыйдә буларак, аларда сурәтләнгән күпчелек вакыйгаларның реаль конкрет җирлеген, ә шәхесләрнең прототипларын ачыкларга мөмкин. Шуның белән бергә, жанрга уйдырмалык та хас. Тарихи җырлар арасында шигъри хыял ярдәмендә иҗат ителгән вакыйгалар да, персонажлар да очрый.

Татар халкының тарихи җырларын күзәткәндә бер нәрсә игътибарны җәлеп итә: җырларның поэтикасы бербөтен түгел. Бу поэтикада халыкның бәетләре һәм лирик җырларына хас күп кенә үзенчәлекләр бергә берләшкән кебек. Күрәсең, шул сәбәпле XX гасырның илленче елларына кадәр татар фольклорында тарихи җырларга әһәмият бирелмәгән, алар функциясен тарихи бәетләр үти дигән караш яшәгән. Мондый фикер өчен тагын бер сәбәп нигез булган дип уйлый алабыз: илленче елларга кадәр тарихи җырлар дип атарлык әсәрләр бик аз җыелган булган. Тупланган кадәресе дә, шигъри үзенчәлекләре ягыннан «чуар» булу сәбәпле, төрле жанрларга кертеп йөртелде. Мәсәлән, качкыннар һәм солдатлар турындагы күп кенә тарихи җырлар бер очракта бәет, икенче очракта лирик җыр яисә дастаннан эпик җыр буларак басыла килгәннәр.

Тарихи җырларның мөстәкыйль жанр булу-булмау мәсьәләсе татар фольклористикасында озак вакытлар бәхәсле булып килде һәм XX гасырның 60нчы еллар ахырында гына үзенең чишелешен тапты. Ф. Урманчеевның «Тарихи җырлар» дип исемләнгән мәкаләсендә татар халык иҗатында тарихи җырларга кагылышлы барлык хезмәтләр, фикер-карашлар өйрәнелеп, тарихи җырларның жанрлык сыйфатлары, яшәү үзенчәлекләре билгеләнә[1].

[1] Урманчеев Ф. Тарихи җырлар // Казан утлары. – 1969. – № 3.



Д. Нәүрүзова рәсеме

**Фольклористикада халыкның үткән тарихындагы аерым социаль-тарихи вакыйгаларга, күренекле шәхесләргә һәм билгесез геройларга багышланган әсәрләрне тарихи җырлар төркеменә кертәләр. Кагыйдә буларак, аларда сурәтләнгән күпчелек вакыйгаларның реаль конкрет җирлеген, ә шәхесләрнең прототипларын ачыкларга мөмкин.**

Яңа чыганаклар табылу, аларны анализлау нигезендә тарихи җырларга карата фикер алышу алга таба да дәвам итә: XX йөзнең 80нче – 90нчы елларында тарихи җырлар мөстәкыйль жанр буларак тикшерелә башлады, җыр жанрының әлеге төренә багышланган саллы мәкаләләр дөнья күрде[2], соңгырак чорда Ф. Урманчеев[3], Б. Бакиров[4], К. Миңнуллин[5] хезмәтләрендә тарихи җырларга шактый киң урын бирелде, Р. Хәкимов тарафыннан тарихи җырлар темасына кандидатлык диссертациясе яклнды[6] (җитәкчесе – Ф. Урманчеев), шул ук темага монография дөнья күрде[7].

### ШӘРУК БЕГЛЫЙ

«Тарихи җырларның аерым төр буларак барлыкка килүе XIII-XV йөзләргә караса да, чәчәк ату дәвере XIX йөзгә туры килә», – дип билгеләли К.М. Миңнуллин. Чыннан да, нәкъ менә шул чорда татарларда качкыннар турындагы җырлар популярлаша. Әлеге циклдан «Шәрук беглый», «Хәмидулла качкын», «Дашкай» («Ташкай») һәм башка җырларда сүз ачлык-ялангачлыктан, патша армиясеннән, алпавыт-түрәләрнең туктаусыз эзәрлекләвеннән качып, урманнарда гомер кичерүче качкыннар турында бара. Әлеге категория кешеләргә мөнәсәбәтле мондый җырлар чынбарлыкта булган хәлләргә нигезләнә, шул вакыйгаларда катнашкан шәхесләрнең кайгы-хәсрәтле, фаҗигале тормыш юлы хакында сөйли.

Кайбер тарихи җырларның баш геройлары турында халыкта күп санлы риваятьләр дә билгеле. Әйтик, «Шәрук беглый»ның тарихы түбәндәгедән гыйбарәт: «Шәрук узган гасыр ахыры һәм бу гасыр башында элекке Самара губернасында яшәгән. Яшьтән үк батырлыгы белән танылa, солдатка каралганчы үз авылында һәм тирә-юньдә яшәүче күп кенә бай түрәләргә зыян ясый. Армиягә алына да кача. Аны тотып төрмәгә ябалар. Озак та үтми, тагын качып китә һәм качкын булып урманда яши. Ул үзенең тугыз иптәше белән бергә алпавыт, байларның котын алып тора, алардан талаган акчаны, мөлкәтне авыл халкына, ярлыларга өләшә. Шуңа күрә халык Шәрукка теләктәшлек күрсәтә, аны яклый һәм саклый. Алай да Шәрукны тотып, сөргенгә җибәрәләр. Киткәндә Шәрук үзенә атап чыгарылган җырларны җырлый»[8]:

Яшь вакытта үстем авылымда,
Әти-әни кабәм кулында.

---

[2] Мухаметзянов М., Ахметшин Б.Г. Татарские исторические песни // Фольклор народов РСФСР. – Уфа, 1984; Бакиров М. Үзенчәлекле жанр буларак бәетләр // Яхин А.Г., Бакиров М.Х. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе. – Казан, 1979; Надиров И. Татар фольклор мирасының фәнни җыелмасы // Татар халык иҗатының хәзерге торышы. – Казан, 1988. – Б. 87-94; Надиров И. Поэтические особенности исторических и лирических песен // Поэтика татарского фольклора. – Казань, 1991; Исхакова-Вамба Р.А. Татарское народное музыкальное творчество. Традиционный фольклор. – Казань, 1977. – 264 с.
[3] Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 175-181; 246-249; 280-287.
[4] Бакиров М.Х. Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 176-197.
[5] Миңнуллин К.М. Һәр чорның үз җыры. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 58-60.
[6] Хакимов Р.Ф. Исторические песни в татарском фольклоре: дисс. канд. филол. наук. – Казань, 2012.
[7] Хакимов Р.Ф. Исторические песни в татарском фольклоре. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – 172 с.
[8] Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. – Казан, 1988. – Б. 382.

Үсеп житкәч, авыр хәсрәт күрдем,
Газап чиктем йөргән юлымда.
Самат урманнары бигрәк зур,
Качкыннарга михнәт бигрәк зур.

### БОЛГАРДАНМЫ КИЛӘСЕЗ?

Болгар чорына караган жыр үрнәкләре хакында Г. Тукай болай ди: «Мәгъмүр болгар шәһәрләре, болгар авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр... Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә... калдылар, алар сәламәт әле, алар яңгырый әле»[9]. «Суар кешеләре жыры», «Әтил суы ака торур» XI гасырда Мәхмүд Кашгари тарафыннан Идел буе болгарларыннан язып алынган һәм «Диване лөгатет төрк» сүзлегендә китерелгән. Бу чорга караган «Болгар иленең кызлары», «Болгарданмы киләсез?», «Болгар ятимәләре», «Шәһре Кашан», «Шәһре Болгар» исә – борынгы кулъязмалар аша мәгълүм ядкарьләр. Боларының нәкъ менә Идел буе Болгары чорында түгел, бераз соңрак ижат ителгән булулары да бик ихтимал. Әмма шунысы әһәмиятле: әлеге әсәрләр татар халкы тарихының Идел буе Болгарына турыдан-туры мөнәсәбәте барлыгын, халыкның этник аңында һәм тарихи хәтерендә Болгар чорының ныклы урын алган булуын күрсәтә. Өстәвенә аларда чал заманнарның аерым тарихи вакыйгалары жанлана. «Шәһре Кашан» турындагы жыр уңае белән М. Бакиров болай яза: «Әсәрдә сүз борынгы Болгар шәһәре Кашанның даны һәм фажигале язмышы турында бара. Бу шәһәр көньяктан килә торган кәрван юлы белән су юлы кисешкән жирдә – Каманың уң як ярына урнашкан булган. ...Тарихи һәм археологик мәгълүматларга караганда, Кашан Болгар дәүләтенең беренче йөзләреннән XIV йөз ахырына кадәр яшәгән. 1391 елда Кашанны Новгород һәм Устюг ушкуйниклары (елга юлбасарлары яки пиратлары) талаганнар. 1396 елда исә Мәскәү кенәзлеге гаскәрләре яу килеп бөлдергән. Шул ук чорда шәһәрне Аксак Тимернең жимерүе турында да легенда-риваять бар»[10].

Тарихи яктан «Болгар иленең кызлары», «Болгар ятимәләре» турындагы жырлар да игътибарга лаек. Алар борынгы Болгарда коллар белән сәүдә итү нәтижәсендә туган драматик хәлләрне гәүдәләндерәләр. Билгеле булганча, коллар белән сәүдә итү Болгар дәүләте икътисадында зур урын тоткан. Алар Болгар шәһәренең үзендә дә, шулай ук көнчыгыш илләренә жибәреп тә сатыла торган булганнар. Тарихи жырның эчтәлеге бәлки бераз соңгырак чордагы вакыйгаларны, әйтик, XIV йөздәге хәлләрне гәүдәләндерә торгандыр, чөнки бу чорда да әле Болгар дәүләте, элекке күләмдә ук булмаса да, кол сәүдәсе белән шөгыльләнгән.

Болгар иленең кызлары
Чикләвекләр ашап үскәннәр,
Дошманнарга улжа (табыш. – **Л.М.**) булып,
Кол базарга барып төшкәннәр.

### МӘДРӘСӘ ШӘКЕРТЛӘРЕ ИЖАТЫНДА ТАРИХИ ЖЫРЛАР

Татар халкының шигъри ижатын баетуга үз вакытында мәдрәсә шәкертләре мактаулы өлеш кертkәннәр. Алар ижат иткән бәетләр, жырлар, садалар халык арасында житди тәрбияви роль уйнаган. «Шәкерт садалары» исеме белән мәгълүм тарихи жырлар үзләре бер шәлкем тәшкил итә, алар – укымышлы, фикерле кешеләр тарафыннан ижат ителгән фәһемле әсәрләр. Бу төр ижатта тарихи вакыйгалар, үткен фикер, шул исәптән, жәдитчелек хәрәкәте идеяләре дә чагылыш тапкан:

Бергәләшеп мәктәп ачыйк,
Наданлыкны аска басыйк,
Шулай итеп, без яшьләрнең
Гыйлем илә күзене ачыйк.

---

[9] Тукай Г. Әсәрләр. Биш томда. Т. 4. – Казан, 1985. – Б. 173-174.
[10] Бакиров М. Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан, 2008. – Б. 178.

Шунысын әйтергә кирәк, бер төркем садаларның авторлары мәгълүм. Берничә саданы, мәсәлән, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең алдынгы шәкертләре Гарифҗан Мостафин, Муллахмәт Бәдигый, Вәсим Солтановлар иҗат иткән. Алар башка шәкертләр тарафыннан күчерелгәннәр, халыкка таратылганнар. Тарихта 1907 елда Оренбургта «Шәкерт садалары» дигән исем белән җыентык басылып чыкканлыгы билгеле, әмма ул, полиция кулына эләгеп, зарарлы китап дигән сылтау белән юк ителгән. Шәкерт садаларының, сакланып калып, XX йөзнең ахырына исән-имин килеп җиткән текстлары Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан дөнья күргән академик «Татар халык иҗаты»ның «Тарихи һәм лирик җырлар» (Казан, 1988) китабында дөнья күргән. Институтның Кулъязма мирас үзәге фондларында да шәкерт дәфтәрләре саклана, алар фольклорчы галимнәр тарафыннан татарлар яшәгән төрле төбәктә 1970-1980 елларда язып алынганнар. Шәкертләр иҗатына караган тарихи җырларда «милләт алгарышы – укып гыйлем туплауда», «бирешмичә алга бару өчен белемле булу – төп шарт» дигән фикер үткәрелә:

Газиз милләткә ихлас хөрмәткә,
Ирешеп хикмәткә, укыйк, шәкертләр.
Бетсен наданлык, бер булсын халык,
Бергә кузгалыйк, укыйк, шәкертләр.

**ПУГАЧАУ**

Татар халкының тарихи җыр дип аталган җырларыннан кайберләре чыганакларда башка жанр исеме белән теркәлгән булырга да мөмкин. Әмма алар үзләренең жанр билгеләре белән тарихи җырга якын ядкарьләрне тәшкил итәләр. Әйтик, «Пугачау» җырының төрле җыентыкларда бәет исеме белән басылып йөрүе мәгълүм. Үзенең структурасы, эчтәлеге һәм поэтикасы белән ул, бәетләргә түгел, ә нәкъ менә тарихи җыр жанрына якын тора, шуны искә алып, бу текстны халкыбызның тарихи җыры дип карау дөресрәк булыр:

Пугачау патша бар диләр,
Постау бишмәтләре тар диләр,
Җаек та буе яу җирләрен
Айкап та йөргән шул диләр.
Пугачау патшаны күрсә идек,
Алларыннан буй бөгеп узса идең,
Аргамак менеп, дан тотып,
Җаек яуларында йөрсә идең.

1773-1775 елларда Россиядә Крестьяннар сугышы җитәкчесе, үзен император Петр III дип атаган ялган патшаларның иң мәгълүме, дон казагы Емельян Пугачев исеме заманында халык иҗатында бик популяр булган. Гадел патша килүгә гомере буе өметләнеп яшәгән халык әлеге образны бик теләп кабул иткән. Пугачевка бәйле тарихи һәм тарихи-топонимик риваятьләрнең бүгенге көндә дә актив яшәвен истә тотсак, үз чоры өчен әлеге персонажга багышланган тарихи җырларның иҗат ителгән һәм таралыш алган булуы гаҗәп түгел. «Пугачау» җыры Идел-Урал буйларында барган Крестьян сугышлары вакыйгаларын һәм татарлар яшәгән урыннардан узган атаклы Пугачев «патша» образын гәүдәләндерүе белән кыйммәт.

Татар тарихи җырларында сурәтләнгән чор, вакыйгалар болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Тематик яктан карасак, татарларның Идел буе Болгары вакыйгаларына бәйле, Казан ханлыгы чоры, XVIII йөз ахыры вакыйгаларына мөнәсәбәтле, Беренче бөтендөнья сугышы, качкыннар һәм торткыннар белән бәйле вакыйгаларны чагылдыра торган, патша армиясендә татарлар язмышын бәян итүгә багышланган, Октябрь инкыйлабына һәм гражданнар сугышы вакыйгаларына карата чыгарылган, шулай ук мәдрәсә шәкертләре иҗаты булган садалары һәм җырларыннан гыйбарәт. 1773-1775 еллардагы крестьян сугышын, аның җитәкчесе Е. Пугачев, милли каһарманнар Салават батыр белән Бәхтияр шәхесләрен, 1812 елгы Ватан сугышы чорын, патша армиясенә хезмәт итү вакыйгаларын яктырткан тарихи җыр үрнәкләре дә сакланып калган.

## ТАРИХИ ҖЫРЛАРДА – ХАЛЫК ИҖАТЫ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Лексик составы, тел-стиль, сурәт-тасвир чаралары ягыннан тарихи җырлар татар халык җыр традицияләренә шактый якын һәм аваздаш. Халык лирикасының төп өлеше хис-кичерешләр агышына, психологик сюжетка нигезләнә. Моннан аермалы буларак, тарихи җырларның нигезендә вакыйгалылык, сюжет ята. Тарихи җырда конкрет тарихи шәхес тормышында булган вакыйгаларны хикәяләү, халык дастаннарындагыча, эпик планда алып барыла. Тарихи җырларның бу үзенчәлеге аларның зуррак күләмле булуын тәэмин итә. Лирик җырлар күп дигәндә биш куплеттан торса, тарихи җырларның сигез, ун, унике куплетлылары бар. Аерым җырларның күләме исә егерме-утыз куплетка җитә. Әйтик, «Әбделмән купис» – унтугыз, «Качкынның михнәте зур» – егерме өч, «Дашкай» утыз куплетлы.

Вариантлылык җәһәтеннән тарихи җырлар арасында да бик киң таралганнары бар. Әйтик, вариантларының күплеге Әбделмән купец турындагы җырларның шактый киң регионда, бигрәк тә татар-мишәрләр яшәгән төбәкләрдә популяр булганлыгын күрсәтә. Монда шуны да искәртү кирәк: бу җырның күп төрле вариантлары өчен нигез булган оригиналь строфалар саны унсигездән артмый. Әмма алар төрле якта, төрле кешеләр хәтерендә бик күп вариантлар рәвешендә яшиләр.

Тарихи җырлар – чынбарлык вакыйгалары һәм мәгълүм шәхесләрне лиро-эпик гәүдәләндерә торган әсәрләр. Аларның һәркайсының диярлек реаль вакыйгага нигезләнгән аңлатмасы була. Тарихи җырга мондый өстәмәләр информантлар сөйләгәннән язып алына. Тарихи җырны башкаручы башта җырга бәйле вакыйганы бәян итә, аннан соң җырны башкара, шул рәвешчә, җырның эчтәлеге тагын да тирәнәя төшә, мәгънәсе киңәя. Әлбәттә, тарихи җырлар янәшәсендә торырга тиешле мондый аңлатмалар информантның мәгълүматлы булу-булмавына нык бәйле.

**Халык лирикасының төп өлеше хис-кичерешләр агышына, психологик сюжетка нигезләнә. Моннан аермалы буларак, тарихи җырларның нигезендә вакыйгалылык, сюжет ята. Тарихи җырда конкрет тарихи шәхес тормышында булган вакыйгаларны хикәяләү, халык дастаннарындагыча, эпик планда алып барыла.**

Җырның тарихына бәйле вакыйгаларның кайберләре, төрле елларда матбугатта басылып, сакланып калган. Әйтик, «Заһидулла качкын» җыры персонажы Заһидулла узган гасыр урталарында яшәгән атаклы качкын булган. Аның маҗаралары турындагы риваятьләр Чиләбе өлкәсенең Коншак районына кергән күп кенә авылларда язып алынган. Аларның кайберләре «Татар халык иҗаты» академик күптомлыгының «Риваятьләр һәм легендалар» китабында (Казан, 1987, Б. 93) басылып та чыккан. Әмма Заһидулла турындагы җырларда аның качкынлык язмышына караган конкрет билгеләр, сурәтләр бик аз сакланган, строфаларны гомум репертуарда очрый торган һәм язмыш турында уйлануларга нигезләнгән мәгълүм җырлардан тора дип тә бәяләргә мөмкин булыр иде. Шул ук вакытта качкынлык, билгеле бер чорда халык язмышында очрый торган күренеш буларак, тарихи җәһәттән игътибарга лаек.

Халык җырларында кешелек дөньясы үткән юлның һәр баскычы үзенчәлекле рәвештә тасвирлана, сәнгатьчә сурәтләнә. Тарихи җырларда реаль вакыйгалар һәм билгеле шәхесләр чагылыш тапкан. Алар тыңлаучыга эмоциональ тәэсир итү һәм идеология коралы функциясен башкарган, заманның әхлак нормалары һәм таләпләре белән бәйләнештә торып, милләт һәм ил тормышында мөһим урын алып торган, тәрбия чарасы ролен үтәгән.

# КЫЯФӘТНАМӘ – МИФМЫ, ЧЫНБАРЛЫКМЫ?

*Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,*
*язучы, әдәбият белгече*



***Бик борынгы заманнардан ук кешеләр, үзара аралашканда, бер-берсенең кыяфәтенә, аеруча йөз-чыраена, башына, гәүдә төзелешенә карап, каршысында торган кешенең холык-фигылен, тәртибен, табигатен, сәламәтлеген, хәтта уй-ниятләрен белергә тырышканнар. Бу үзенчәлекле «юрамыш-сынамыш»ларны бер төшенчәгә җыеп, «кыяфәтнамә» дип йөртә башлаганнар.***

Шул рәвешле саллы-саллы трактатлар, магик һәм «психологик» кулланмалар, «тыйб» китаплары, ярым мифик, ярым фәнни рекомендацияләр барлыкка килгән. Аларның барысын бергә туплап, татар халкының мифологик мирасы кысаларында өйрәнергә мөмкин. Ни өчен миф? Чөнки күпчелек кыяфәтнамә берәмлекләре кайчандыр нindidер миф, риваять, легенда нигезендә барлыкка килгән. Башка төр юрамышлар кебек, бу очракта да кыяфәт белән бәйле юрамышларның тууына сәбәпче булган күпчелек мифлар эзсез югалган, әмма «исән калган» кыяфәтнамә мифлары логикасына нигезләнеп, ул мифларны да күпмедер дәрәҗәдә күзалларга мөмкиндер.

Мәсәлән, борынгы ышанулар буенча, кешенең сул ягы – эти ягы, уң ягы әни ягы дип бәян ителә. Шул рәвешле, уң як бөер һәм уң як үпкә әнигә карый, ә сул як бөер белән сул як үпкә эти ягына буйсына. Кешенең эчке органнарының эти яки әни ягында булуы хакында һәр мифологик системада мәгълүмат бар. Йөрәк белән хәл ничек тора соң? Ул, әлбәттә инде, ирлек ягында кала. Җенес органнары тагын да катлаулырак ышанулар системасына карый. Йөз-бит белән бәйле кыяфәт юрамышлары еш кына шушы мифологик тәгълиматка буйсына да инде. Әйтик, әгәр кешенең борыны сулга авыш булса, димәк, аның әни ягы эти ягына караганда активрак эшли. Һәм киресенчә. Ә инде бернинди дефекты да булмаган тигез борын әни ягы белән эти ягының тулы гармониядә яшәве хакында хәбәр итә. Гомумән, кыяфәтнамәдә борын юрамышлары мөһим роль уйный. Мәсәлән, уң борын тишегеннән

сулау җылыта, ул – Кояш сулышы; сул борын тишегеннән сулау суыта, ул – Ай сулышы. Шул нигездә борын белән сулау үзенчәлекләре хакында әллә күпме юрау элементы барлыкка килгән. Аларның күбесен бүгенге табиблар да инкяр итми.

«Сул як, уң як» принцибына корылган, борыңгы дини мифын саклап калган кыяфәтнамә юрамышларына тагын бер мисал: «Кешенең иңбашы (кулбашы) уң якка иңеп, басылыбрак торса – яхшы кеше, гадел, ихлас. Халык мифологиясе буенча, уң як иңдәге фәрештә – изге фәрештә. Ә инде кешенең сул як иңбашы (кулбашы) басылыбрак торса, безнең алда – эчкерле кеше, яшертен, астыртын эш йөртүчән бәндә; аның иңендә явыз рухлар, шайтани затлар утыра.

Кыяфәтнамә юрамышларын шәрехләүне кешенең башына, йөз-битенә нисбәт ителгәннәреннән башлап китсәк, дөрес булыр. Чөнки элек-электән кешенең акыл-зиһен дәрәҗәсе аның

> «
> *Бик борынгы заманнардан ук кешеләр, үзара аралашканда, бер-берсенең кыяфәтенә, аеруча йөз-чыраена, башына, гәүдә төзелешенә карап, каршысында торган кешенең холык-фигылен, тәртибен, табигатен, сәламәтлеген, хәтта уй-ниятләрен белергә тырышканнар.*
> «



Д. Нәүрүзова рәсеме

башы, баш төзелеше белән бәйләнгән дип каралган.

Мәсәлән:

– Башы артка чыгыбрак торган кеше артык акыллы, сабыр була, дип уйланылган. Ягъни, акылы артык күп булганлыктан, аның башы артка, хәтта аска басылып төшкән.

– Башы маңгай өлешендә алгарак чыкса, бу кеше гаять зирәк һәм сизгер булырга тиеш, дип уйланылган. Киң маңгай яки текә маңгай да кешенең зирәклегенә ишарә. Ягъни, бу кешенең акылы һәрвакыт уяу, сизгер, һәрвакыт алдарак...

– Очланыбрак торган башлы кеше артык хыялланучан һәм уйга батучан була. Ягъни, мондый кешенең башы никадәр очлы булса, аның уенең да очы-кырые юк, имеш...

– Маңгае тар кешенең холкы тар. Ягъни, мондый кеше акылга сай, ә акылга сай кеше теләсә нинди мөгез чыгарырга да мөмкин.

– Маңгай кешенең психикасына ишарә. Маңгайдагы аркылы сырлар – курку, гаҗәпләнү галәмәте, кайвакыт мин-минлекне белдерә. Маңгайдагы буйбуй сырлар – кайгы-хәсрәт билгесе, бу кешенең күпне күргәнен аңлата. Аркылы сырлар буй сырлар белән катнаш булганда – иза чигү, чарасызлык, ялгызлык, кайгы-хәсрәт билгесе. Бу – меланхоликларга хас сыйфат.

– Башын югары күтәреп, башын артка кәкрәйтеп йөрсә – тәкәббер һәм мин-минлеге көчле кеше.

– Башының арт чүмечен еш тотучан булса – сак эш итүчән һәм башкалар.

Җилкә-муен белән бәйле кыяфәт юрамышлары:

– Җилкәсе чокыр кеше – ялкау кеше. Андый кешенең җилкә чокырына яңгыр тамчысы тамса, ул тамчы көне буе шул ялкау бәндә җилкәсендәге чокырда йөрергә мөмкин, имеш.

– Җилкә чокыры тирән булса – ялганчы була, дигән фараз да бар.

– Озын муен – һәрвакыт алда барырга омтылучы, юлбашчы булырга тырышучы, әмма шул ук вакытта оялчанрак кеше.

– Тыгыз һәм кыска муен – акыллылык билгесе. Табиблар өчен кызык тоелырдай мәгълүмат бар: муены тыгыз һәм кыска кеше кан тамырлары авыруына дучар. Борынгы «тыйб» фәне буенча, үпкәсе авыру булса яисә сулышы буылудан (астмадан) интексә, авыру ягыннан муены тагын да юанрак булыр.

– Озын ябык муен нервылары эштән чыккан кешегә нисбәт ителә; әгәр кан тамырлары кабарып торса, ул кешедә яшәү мәгънәсе калмаган, аның психикасы тузган булыр.

– Муены алга авышып торса – укымышлы, әмма бик усал булыр.

– Муены уңга авыш – акылы үзенә генә көйләнгән (эгоист кеше).

– Муены сулга авыш – алдакчы.

– Муены артка кәкрәйгән – тәкәббер.

**БОРЫН БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЮРАМЫШЛАР:**

– Кырык яшькә кадәр борын рәвеше уртача озынлыкта һәм уртача зурлыкта булып формалашса, бу – яхшы холыклы кешегә хас.

– Кыска, җәлпәк борын – тәвәккәл һәм үҗәт, үзсүзле кеше.

– Зур борын – тиз кызучан.

– Борын тишекләре бик яхшы – көчле, кыю; борын тишекләре зәгыйфь – сүлпән, авыр сабырлы.

– Борын очы гына асылынып торса – сизгер, әмма нервылары какшаган.

– Биек бөкре борын – тынгысыз, чыгырыннан тиз чыгучан, масаючан.

– Әгәр бөкресе генә биек булса – үз-үзен генә ярата.

– Очлы борын – психик халәте тотрыксыз.

– Кыек борын – физик һәм психик халәте тотрыксыз, алда әйткәнебезчә, организмның ата-анасы тәңгәл (пар) килмәгән була.

Кешенең уй, зиһен, акыл көчен дә борын белән юраганнар:

– Зур борын – күп уйлаучан.

– Ян-яктан борын тишекләре кабарып торса – ачык фикерле алмый, тотнаксыз.

– Кыска, киң, җәлпәк борын түбән интеллектлы ирләргә хас.

– Борын очы өскә карап торса – көнкүрешне, яшәешне аңлый алмый.

**КЕШЕНЕҢ АВЫЗЫ ДА КҮП НӘРСӘ БЕЛДЕРГӘН.**

Мәсәлән:

– Зур авыз – матур һәм күп сөйләүчән кеше. Акылга сай кеше.

– Кечкенә, уймак авыз – моңлы кеше, җырларга ярата. Бик тиз сагышка таручан.

Ирен юрамышлары:

« *Элек-электән кешенең акыл-зиһен дәрәҗәсе аның башы, баш төзелеше белән бәйләнгән дип каралган.* «

– Ирене юка кеше усал булыр.

– Киң иреннәр – тиз гашыйк булучан һәм мәхәббәттә, гыйшыкта талымсыз кеше.

– Шакмак ирен (иреннәрнең чите почмакланып тора) – максатына ирешү өчен барысын да эшләргә әзер, тырыш, уңган кеше.

– Сузымча ирен – тар фикерле, әмма рәхәт тормышта яшәячәк.

**БИТ-ЙӨЗ БЕЛӘН БӘЙЛЕ КЫЯФӘТНАМӘ ЮРАМЫШЛАРЫ:**

– Тулы алсу йөзләр – тиз ышанучан, артык самими кеше.

– Бит очында түгәрәк чокыр (халык телендә – «мәхәббәт чокыры») – үбешергә, сөешергә яратылган кеше (аеруча хатын-кызларга карата әйтелә).

– Таба (киң) йөз – авыр сабырлы, төпле акыллы, озын гомерле.

– Озынча йөз – аумакай, куркак, ихтыяр көченнән мәхрүм кеше.

Кашлар, керфекләр хакында берничә кыяфәт юрамышы:

– Калын кашлар – усал кеше.

– Ай-кашлар – ихласлылык, дәртлелек билгесе.

– Тоташкан кашлар – зиһенлелек, зирәклек, хәтта хәйләкәрлек билгесе.

– Каш арасы тар – гомере кыска булыр.

– Керфеге озын кешенең гомере кыска була.

**КҮЗЛӘР БЕЛӘН БӘЙЛЕ КЫЯФӘТ ЮРАМЫШЛАРЫ:**

– Зур күзләр – бик дәртле һәм хәйләкәр кеше.

– Кысык күзләр – көчле ихтыярлылык һәм түземлелек, шул ук вакытта үзсүзлелек билгесе.

– Көл төсле күз кабагы – организмда әчелек күбәйгән. Мондый кеше күзгә күренеп усаллана, кырыслана.

– Ала күздә акыл булмый, майлы күздә ягым (ягымлылык) булмый (халык әйтеме).

– Алан-йолан каранучы кешедә өмет юк (халык әйтеме).

– Күзе очлы угры булыр (халык әйтеме).

– Күзнең агы бары тик ике урында – күз кырыйларында гына күренеп торса – бу сәламәт кеше. Ак аның аскы кабак өстендә дә күренеп тора башласа – начар фал. Бу – организмның яшәү энергиясен югалтуы хакында сөйли. Шулай ук авырулар билгесе итеп тә карала.

**КҮЗЛӘРНЕҢ ТӨСЕ БУЕНЧА ЮРАУ ДА КИҢ ТАРАЛГАН.**

Бу хактагы мәгълүматларны берләштерсәк, шактый мавыктыргыч һәм гыйбрәтле кыяфәтнамә барлыкка килә. Халыкның мифологик мирасында сакланып калган «рекомендацияләр» дә шунда ук.

Ачык коңгырт-соры күзле кешеләр үзләрен һәрвакыт башкаларга караганда әйбәтрәк хис итәләр. Кагыйдә буларак, алар теләсә нинди авыр кичерешләрдән җиңел чыгалар һәм озак төшенкелеккә бирелмиләр.

Сары күзле чибәрләрне, барыннан да бигрәк, алда күпме гомер калуы хакындагы сорау борчый. Җавабы мәгълүм: тормыш юлдашларыгызны еш алыштыра торган булсагыз, озак яшәмәячәксез. Сары күзле ирләрне исә профессиональ мәсьәләләрне ничек хәл итү турындагы сорау дулкынландыра. Аларга киңәш шул: үзегезгә хас булганча хәл итегез – кыенлыкларга күләп карасагыз, бик тиз уңышка ирешерсез.

Зәңгәр күзлеләр, унбиш яшьтән алып кырык яшьләргә кадәр, җанлы тормыш белән яшиләр. Аннары төшенкелеккә биреләләр, күңел тынычлыгын югалталар. Хатын-кызларга аның турында дусларының нәрсә уйлавын даими беләсе килү теләге тынгы бирми һәм бу тәр кешеләр, үтә дә үҗәтләнеп, бу хакта ачыкларга тырышалар. Ә менә зәңгәр күзле ир-атларны гомер буе профессия сайлау борчый. Уңай, дөрес дип тапсалар, алар үз профессияләрен теләсә нинди минутта алыштыра алалар. Ахырда алар күбрәк иҗат белән бәйле профессия сайлыйлар.

Коңгырт-кара күзле кешеләрнең кырык яшьтән соң гомерләренең иң яхшы вакыты башлана. Урынсызга шикләнү – коңгырт-кара күзле кешеләрнең иң зур кимчелеге. Дөрес, моны аклап та була: кагыйдә буларак, бу хатын-кызларны гомерләре буе бер генә тугры дус озатып бара, калганнары, иртәме-соңмы, аңа хыянәт итәләр. Ир-атлар исә теге яки бу серне кемгә дә булса ышанып сөйләргә ярау-ярамавын хәл итәргә тырышалар. Серләргә килгәндә, алар коңгырт-кара күзле ир-атларда бик күп.

Соры күзлеләргә һәрвакыт уңыш юлдаш була. Аларга бәхетле йолдыз сабый чактан ук елмая башлый. Әмма алтмышка якынлашкач, ул йолдыз күк йөзеннән кинәт кенә юкка чыга. Ә күнегелгән уңышлар сары кара сагыш белән алышына. Гомернең соры чоры башлана. Һәм соры күзлеләр үзләрен дөньядагы иң ялгыз кеше итеп хис итәләр. Соры күзле хатын-кызлар исә бик мавыгучан (азартлы) була.

Яшел күзлеләрнең иң бәхетле чагы – яшьлек. Алар тормышындагы иң әһәмиятле вакыйгалар ике мәртәбә: унбиш яшьтән соң һәм егерме биш яшьтән соң була. Яшел күзле хатын-кызларның күпчелеге бик иртә никахлашса да, алар, тормыш юлдашы сайлаганда, бик таләпчән булалар һәм булдыклы ирләрне сайлыйлар.

Йөз-бит белән бәйле тагын берничә халык телендә киң таралган ышану-юрамыш игътибарны җәлеп итә.

**КОЛАКЛАРГА КАРАП ЮРАУ:**

– Зур, калкан колак – димәк, безнең алда табигать җанлы кеше, табигать, хайваннар белән генә түгел, кешеләр белән дә нык аралашучан ихлас кеше. Ул, гомумән, кешеләрдән башка яши алмый, аның гел халык арасында, кеше күзендә буласы, мактау ишетәсе килеп тора.

– Кечкенә колак – ялгызлык, сагыш билгесе.

– Колагы йонлы кол булыр (халык әйтеме).

**ТЕЛ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЮРАМЫШЛАР:**

– Зур, җәлпәк телле кеше күңелчән, көлдерергә яратучан була.

– Очлы тел – усал.

– Озын тел – астыртын.

– Кыска тел – тыйнак, әйбәт кеше.

**МЫЕК-САКАЛ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЮРАМЫШЛАР:**

– Каты сакаллы кеше – каты бәгырьле.

– Мыеклы хатын-кыз – бәхетле хатын-кыз.

– Сакалы зур, башы кечкенә булса – ахмаклык билгесе. Каюм Насыйри да «Фәвакиһел-җөласа фил-әдәбият» китабында: «Сакалның зурлыгы да гакылга каршы тора икән», – дип яза.

**ЧӘЧЛӘР БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЮРАМЫШЫЛАР:**

– Каты чәч – нык характерлы, хәтта кырыс, усал кеше. Каты чәч – каты күңеллелек билгесе.

– Йомшак чәч – йомшак күңел, нечкә күңел. Йомшак чәчле кеше – хисле кеше. Иҗади зат.

**КЕШЕ ТӘНЕНДӘГЕ МИҢНӘР БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЮРАМЫШЛАР:**

– Муены миңле – бәхетле.

– Күзе миңле – яшьле.

– Авызы миңле – ашлы, мул тормышлы.

– Ирен читендәге миң – дәртлелек билгесе.

– Касыктагы яисә җенси әгъзадагы миң – азгынлык билгесе һәм башкалар.

Миңнәрне формасына, рәвешенә карап та фаразлыйлар:

– Йомры миң – уңай билге.

– Сузынкы миң – тискәре билге.

– Кабарынкы миң – бәхетле язмыш.

Миңнәрнең урнашу тәртибенә карап махсус юрау системасы эшләнгән.

– Маңгайда: уң якта – шөһрәткә омтылучан, акыллы; сул якта – сәерлек, көчсезлек билгесе.

– Күз янында: күзнең тышкы почмагы ягында – тыныч холыклы, үз-үзенә ышанучан, сакчыл; эчке почмагы янында – бик серле, яшерен кеше; борчу күп күрәчәк.

– Каштагы миңнәр: уң якта – бәхет, иртә никах; сулда – авыр никах.

– Колакта миңнәр: мәрхәмәтсезлек.

– Чигәдә миңнәр: уртада – бәхет (бигрәк тә гаилә тормышында); сулда – авырлык, көрәш.

– Яңак сөягендә миң: уңыш, әйбәт тормышта яшәү.

– Авыз янында миң: бәхет, сиземләү сәләте.

– Ияктә миң: зәгыйфь сәламәтлек.

– Борында миң: тормышта җайлы яшәү, сәяхәт, җенси егәрлек.

– Тамакта миң: бай никах, шөһрәтле хыялларның тормышка ашуы.

– Муенда миң: зур уңыш, бәхет, көтелмәгән милек; шулай да яшәүнең баштагы чорында зур сынаулар, уңышсызлык булып ала, ахырга таба зур үсеш көтелә.

– Кул чугында миң: уңыш китерүче табигый сәләт.

– Кулдагы миң: уңда – бәхет; сулда – акча мәхәббәте.

– Җилкәдә миң: авыр һәм катлаулы тормыш.

– Күкрәктә миң: уңда – язмышның яхшы якка, бәхеткә таба борылышы; сулда (ирләрдә) – уңыш һәм бәхет; сулда (хатын-кызларда) – дәртлелек; уртада – яхшы табыш.

– Корсакта миң: үз-үзен яратучан, йомшаклыгына ирек куючан, ялкаулык һәм комсызлык булуы да ихтимал.

– Аркада миң: намуслы, юмарт (шул ук вакытта тәкәбберлек тә юк түгел); әгәр дә миң арканың түбән ягында булса – сиземләү сәләтенә ия, ләкин үзенең йомшаклыгына бик тиз юл куя.

– Кабыргада миң: уңда – куркаклык, мәгънәсезлек; сулда – шул ук сыйфатлар, әмма үзенә карата бераз мыскыллы мөнәсәбәт.

– Ботта миң: уңда – шәфкатьле холык, байлык һәм гаилә тормышында бәхет; сулда – ялгызлык, югалту, шәфкатьле булуга карамастан, ярлылык.

– Тездә миң: уңда – гамьсез һәм ваемсыз никах, акча мәсьәләсендә икеләнүләр (акча тота белмәү); сулда – тынычсызлык.

– Учта миң: нәзакәтлелек; ирләрдә – купшылык; хатын-кызларда – көчлелек, хезмәт сөючәнлек.

– Аяк табанында миң: уңда – юл йөрергә һәвәслек; сулда – зирәклек.

– Аякта миң: ялкаулык.

**АЯК-КУЛЛАР БЕЛӘН БӘЙЛЕ КЫЯФӘТ ЮРАМЫШЛАРЫ:**

– Кулы озынның йөрәге кызу.

– Кулы каты ир карт хатын ала.

– Кул артларының йөнтәс булуы – чын (көчле) ирлекне белдерә.

– Йөнтәс беләк-беләзек – бәхет билгесе.

– Үкчәсенә бәреп йөргән кеше бик көнче була.

– Балтыры йонлы бай булыр.

– Аяк бармаклары тырнагында ак тап – көяз кеше.

**КЕШЕНЕҢ БУЙ-СЫНЫНА КАРАГАН ЮРАМЫШЛАР:**

– Юан кеше нечкә хәйләле булыр (халык әйтеме).

– Үтә исәр буйга үсәр (халык әйтеме).

– Кечкенә уйлы кеше күп ачу йөртә. Бу хакта да халык әйтеме бар:

– Кече казан ташучан,
Кечек кеше ачучан.

– Кечкенә буйлы, җитез табигатьле кеше – максатчыл, уңган-булган кеше.

Шулай да, кеше кыяфәтенә бәйле юрамышларның бер өлешен бүгенге медицина, физиология, психология фәннәре нигезендә аңлатырга мөмкин. Кайбер табибларның, авыруларга диагноз куйганда, өстәмә дәлил рәвешендә, кыяфәтнамә юрамышларын шактый җитди дәрәҗәдә өйрәнүләре һәм кулланулары хакында ишетергә, күрергә мөмкин. Бу очракта борынгылыктан килүче, кеше кыяфәтенә карап хастаны юраучы (чынлыкта диагноз куючы) ышанулар белән бүгенге медицина арасындагы ярашу-килешүләрне ачык калдырып, берничә мисал китерү белән чикләнергә туры килә.

**ӘЙТИК, ШУЛ УК БОРЫН БЕЛӘН БӘЙЛЕ «ТЫЙБ» ФАРАЗЛАРЫ УКУЧЫ ӨЧЕН КЫЗЫК ТОЕЛЫР, МӨГАЕН.**

– Борын сырты тар – үпкәсе авырып җәфалана.

– Кысылган борын яки «кылыч борын» – организмда кальций алмашы бозык, умыртка баганасы авырта.

– Киң борын – полип бар.

– Борын «итек» рәвешле – йөрәк һәм кан тамырлары авыру, нервысы какшаган.

– Асылынып торган борын – сидек куыгы борчый.

– Борын кабарган – бүлеп чыгару сәләте зәгыйфь.

– Калын борын – бүре ыгы (золотуха) булучан.

– Борын очы каты – симергән, организмга артык май тупланган, дөрес тукланмый.

– Борын очы икегә аерылып тора һәм каты – йөрәк өянәкләре булу, йөрәк тибүе бозылу ихтималы бар.

– Борын салкынга сизгер булса, өшеп, кызарып торса – организмда тоз күбәйгән.

– Кирәгеннән артык озын һәм биек борын – җенси салкынлык.

– Шуны да искәртергә кирәк: кеше борынының нинди төстә булуы да аның организмындагы процесслар хакында сөйли дип фаразлыйлар. Түбәндә шундый фаразларның медицина тарафыннан расланган, дәлилләнгән берничәсен тәкъдим итәбез:

– Борын очы кызару – капиллярлар киңәюне, кан басымы күтәрелүне, ашказаны-эчәк эшчәнлеге бозылуны, шулай ук күзәнәкләр яралу сәләте бозылуны белдерә.

– Борын очы шәмәхә төскә керсә – йөрәк тибүе бозылган, кан басымы түбәнәйгән, капиллярлар киңәйгән һәм кан тамырлары эшчәнлеге сүлпәнәйгән.

– Ак борын – капиллярлар кысылу нәтиҗәсе.

*Кеше тәнендәге һәр әгъза, аның кыяфәтендәге һәр чалым, төс, рәвеш организмның хәзерге рухи-психологик хәле, сәламәтлекнең бүгенге торышы хакында хәбәр итә.*

**ЧӘЧЛӘР БЕЛӘН БӘЙЛЕ МЕДИЦИНА ФАРАЗЛАРЫ:**

– Җирән чәч – буыннары ревматизм белән җәфалана.

– Чәч коелу, чәчнең очлары теткәләнү, яргалану – шикәрле ризыкларны күп ашау яисә артык ашау нәтиҗәсе.

– Кыл кебек каты, ак чәч – баш авыртучанлык билгесе.

– Чәчнең иртә һәм тиз агаруы – бавырда, үт куыгында авыру хасил булу.

– Чәч кору-кавыклану – ашказан асты бизе авыруы.

– Кавык – майлы ризыклар һәм аксым белән артык мавыгу нәтиҗәсе.

Шул рәвешле, кеше тәнендәге һәр әгъза, аның кыяфәтендәге һәр чалым, төс, рәвеш организмның хәзерге рухи-психологик хәле, сәламәтлекнең бүгенге торышы хакында хәбәр итә. Безнең ата-бабалар бу «фән»не гомер барышында шактый камил дәрәҗәдә үзләштергән булганнар. Әлеге ярым мифологик, ярым фәнни фаразлар (диагноз) системасы халык медицинасында, имчеләр, дәвачылар практикасында күптән җиренә җиткезеп эшләп куелган булган. Халкыбызның мифологик хәтерендә сакланып калган бу мирасны кабат торгызырга, өйрәнергә һәм көндәлек тормышыбызга кайтарырга бик вакыттыр.

# КАЗ ӨМӘСЕ

*Гүзәлия МУСИНА,*
*Чистай районы Гаделша авылы мәдәният йорты методисты*

**Безнең Гаделша авылы халкы уңган, булган: күп итеп мал-туар, каз-үрдәкләр асрыйлар. Җәй көннәрендә су буйлары казлар каңгылдавыннан, үрдәкләр гүләвеннән тынып тормый. Һәр елны суыткач, ноябрь азагыннан алып декабрь ае буена, хуҗалыкларда каз өмәләре үтә.**





Бер атна алдан барлык туган-тумачага, күрше-күләнгә, дус-ишләргә өмә буласы көн әйтелә. Казларны сую эшенә керешкәнче бераз җырлап, биеп, уен-көлке белән йорт эчен ямьгә төрәләр. Казларны суюны, авылның җиңел куллы, намазлы картына тапшыралар. Өмә башлана. Яше, карты, туганы, күршесе тезелешеп утырып, җырлый-җырлый каз йолкыйлар. Мәзәкләр сөйләп, бер-берсен көлдерәләр.

Казлар суелып, эше беткәч, хатын-кызлар иң беренче канатларын кисеп, хәрам йоннарын алалар. Хәрам йоны мендәр тутырганда эченә кермәскә тиеш, чөнки элеккеге әбиләрдән калган «башны авырттырачак» дигән ырымы бар. Борынгыдан килгән гадәт буенча, кирәксенүчеләр канатны да урлап кына алганнар.

Казлар йолкынып беткәч, хуҗабикә коймак пешерә, аларны каз мае белән майлый, өмәчеләрне сыйлый. Кайнар коймаклар белән чәй эчеп алгач, каз өмәсенә килгән ханымнар казларны вак йоннарыннан чистарту өчен ир-атларга тапшыралар. Һәм алар, үз чиратларында, бөтен шартына туры китереп, казларны өтү эшенә керешәләр.

Өтелгән казларны юу этабы башлана. Юылган казларны көянтәләргә элеп, өмәче апаларсеңелләр чайкарга дип, су буена төшеп китәләр. Хуҗабикә кәрзингә тутырган каз кауырыйларын: «Киләсе елга да казларыбыз күп, симез булсыннар, күмәк-күмәк йөрсеннәр», – дип, матур теләкләр тели-тели, чишмә буйларына, казлар үзләре йөргән су буйларына тарата. Казларны көянтәләргә асып, барганда да, кайтканда да татар халкының милли моңнарын көйләү, җырлашу да бу йоланың матур традициясе.

Каз өмәсе тәмамлангач, өмәдә булган ханымнар мул итеп әзерләнгән табын артында һәркемнең яратып ашала торган тәмле ризыгы – кайнар каз бәлеше белән сыйланалар.

Күп итеп казлар асраган Тәнзилә апа Хәйруллина, Рәмзия апа Фәтхетдинова өйләрендә быел да гөрләп каз өмәләре узды. Әйе, күмәк эш таулар күчерә диләр. Халкыбызның милли йолалары авылдашларны, туганнарны дуслаштыра, берләштерә. Ата-бабалардан калган йолабызны һич кенә дә онытырга хакыбыз юк. Һәр елны су буйларыннан каңгылдашып казлар кайтуы дәвам итсен, хуҗаларын шатландырып, күп булып гөрләп үссеннәр иде!

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан



# «КАУРЫЙ» БӘЙРӘМЕ

***(Фольклор күренеш)***

*Рашания ЗАРИПОВА,*
*Башкортстан Республикасы Туймазы районы Төмәнәк авылы мәдәният йорты җитәкчесе*

*(Хуҗабикә табын караштырып йөри. Шау-гөр килеп бер төркем хатын-кызлар килеп керә. Сәхнәдә мич тора.)*

**Беренче хатын:**
*Исәнмесез-саумысыз,*
*Әй, хуҗалар, кайда сез?*
*Өмәчеләр килеп җитте,*
*Нигә каршы алмыйсыз?*

**Хуҗабикә:** Күрми дә торам, әйдәгез рәхим итегез, түрдән узыгыз! Сезнең хөрмәткә чәй табыны әзерләп йөри идем.

**Икенче хатын:** Эш эшләми торып нинди чәй ди ул?

**Өченче хатын:** Әйе, башта эшне бетерик.

**Хуҗабикә:** Ашау эш калдырмый ул, ахирәтләр! Көз көне үзегез йолкыган казларның мае белән майлап, бик тәмле тәбикмәк пешердем. Әйдәгез, табынга рәхим итегез.

*(Тәбикмәкне мактый-мактый чәй эчәләр.)*

**Беренче хатын:** Ахирәткәем, тәбикмәгең бигрәк уңган. Үзе күпереп пешкән, үзе йомшак. Телеңне йотарлык! Серен безгә дә әйт әле.

**Хуҗабикә:** Сере булмаса да, тәбикмәк пешерү турында такмак белән әйтеп бирим булмаса. Арада яшь кызларыбыз да бар. Алар да колакларына киртеп куйсыннар.

*Тәбикмәкне пешерергә*
*Бик яхшы он аласың.*
*Йомшаграк булсын өчен,*
*Манный ярмасы саласың.*

*Йомыркасын, шикәр комын,*
*Тоз, соданы онытмыйсың.*
*Шуларның барысын бергә*
*Җылы сөттә туглыйсың.*

*Колмак чүпрәсе салып,*
*Яхшылап болгатасың,*
*Күпереп кабарсын өчен,*
*Җылы җирдә томасың.*

*Дүрт-биш сәгать үткәннән соң,*
*Камырың була әзер.*
*Инде тәбикмәгеңне*
*Пешерсәң була хәзер.*

*Кызган майлы табага*
*Апараны саласың.*
*Ике ягы да кызаргач,*
*Тәбикмәкне аласың.*

*Ул пешәдер күпереп,*
*Авыз суын китереп.*
*Тел өстендә тотарлык,*
*Ашап туймаслык булып.*

*Инде кала майлыйсы,*
*Тәмле майны сайлыйсы.*
*Иң соңыннан дусларны*
*Тәбикмәк белән сыйлыйсы.*

**Икенче хатын:** Һай, ахирәт, шундый гади итеп аңлатып бирдең бит, ә!

**Беренче кыз:** Иртәгәгә кадәр ничек түзәргә иде, пешереп карыйсы килә бит!

**Өченче хатын:** Ярар, пешерерсең, кызым, пешерерсең. Ә хәзер эшкә тотынырга вакыт. Без бит өмәгә дип килдек.

*(Идән уртасындагы үрелгән каз оясы тирәли утыралар. Ояда каз каурыйлары.)*





**Хуҗабикә** *(каурыйларны күрсәтеп):* Менә, ахирәтләр, көз көне бергәләп суйган казларның каурыйлары монда. Борын-борыннан безнең ата-бабаларыбыз хуҗалыкта бер нәрсәне дә әрәм-шәрәм итмәгәннәр. Каз каурыйлары белән дә шул хәл булган. Йә каз суйган көнне үк, йә кышкы озын кичләрдә кыз-кыркын, хатын-кызлар җыелышып каурыйларны сыдырганнар. Чөнки каурый мамыгы мендәрләрне тагын да ныграк кабартып җибәрә икән.

«Каурый» өмәләре бик күңелле үткән. Анда җыр-такмаклар да, уен-көлке дә, биюләр дә булган. Егет-җилкенчәк тә килгән, гомумән, үзенә күрә бер бәйрәм булган. Менә без дә бүген шундый бәйрәм ясарга булдык.

Башта эшне эшләп алыйк: каурый сыдыруның да хикмәте бар. Аны дөрес итеп сыдыра белергә кирәк. Менә хәзер Кәнифә апагыз яшь кызларга ничек эшләргә икәнен күрсәтеп бирер.

*(Берничә каурыйны сыдырып күрсәтә.)*

**Беренче кыз:** Кәнифә апа, бу мамыклардан ясалган мендәр кемгә була?

**Кәнифә апа:** Төпчегем Сәриягә. Алла бирса, киләсе елга укуын тәмамлый. Дуслашып йөргән бик акыллы егете дә бар. Бәлки берәр елдан шаулатып туй да ясап куярбыз. Заманасы башка булса да, бирнә, пар мендәрләр белән килен төшерү йоласы әле дә бар бит.

**Өченче хатын:** Дөрес әйтәсең, Кәнифә апа! Без дә пар мендәрләр белән килен булып төшкән идек. Аллага шөкер, өч дистә ел парлы булып гомер итәбез.

**Раушания:** Ахирәтләр, гел утырып торып аякларыгыз оеп бетмәдеме? Әйдәгез, булмаса, бер җырлап-биеп алыйк.

**Хатыннар** *(бергә):* Әйдәгез, әйдәгез.

*(«Сәрия» җыры башкарыла.)*

*(Бер кыз кинәт кенә биюдән туктап кала.)*

**Беренче кыз:** Кызлар, ишетәсезме? Ишек шакылдаталар түгелме?

**Икенче кыз:** Әйе шул!

**Беренче хатын:** Карале син боларны! Без берни ишетмибез, ә кызлар шау-шу арасында да ишек шакыганны ишетеп алганнар.

*(Ишекне ачалар, өйгә гармун уйнап, җырлап, ирләр, егетләр килеп керә.)*

**Беренче егет:** Исәнмесез, кызлар!

**Икенче егет:** Өмәләр котлы булсын!

*(Хуҗабикә, егетләр арасында үзенең тормыш иптәшен дә күрә.)*

**Хуҗабикә:** Әйтәм аны чыгып югалган иде, егетләр җыеп йөргән икән!

**Хуҗа:** Бәй, шундый бәйрәмгә кызлар җыелгач, егетләрсез була димени!

**Хуҗабикә:** Бик яхшы булган әтисе. Эшебез дә азагына якынлашып килә. Эш беткәнче, безгә гармун уйнап, җырлап торырсыз. Аннан инде яшь чактагы җырлы-биюле уеннарны искә төшереп алырбыз, шулай бит, кызлар?

**Өченче хатын:** Күрегез әле, минем хәчтерүш тә егетләр исәбеннән йөргән була!

**Өченче хатынның ире:** Алай димә, хатын! Яшь чагыңда миннән дә әйбәтрәген таба алмаган идең әле. Аулак өйләрдә мин җырлаганда күзеңне дә алмый утыра идең.

**Өченче хатын:** Шул җырыңа алданып чыктым да инде мин сиңа.

**Өченче хатынның ире:** Соң, хатын, начар яшәмибез бит!

**Хуҗабикә:** Карагыз әле бу икәүне! Егет белән кыз диярсең! Ярар, калганын кайткач сөйләшеп бетерерсез. Каурыйлар сыдырылып бетте, мендәрләр ясарга вакыт җитте.

*(Хуҗабикә чигелгән мендәр тышлары бирә.)*

**Беренче хатын:** Кызлар, егетләр, мендәрләргә мамык тутыруның да йоласы бар. Мендәр тышын ике яктан тотып торырга бер егет белән бер кыз кирәк. Парлап матур гомер кичергән апа белән абый, изге теләкләр теләп, мамыкны тутыралар.



*(Бер егет белән бер кыз, гаиләле парлар чыгып, мендәргә мамыкны тутыралар.)*

**Хатын:**
*Мамыклар белән тулган,*
*Мендәрләр йомшак булсын.*
*Парлы мендәр өсләрендә*
*Гашыйклар гына кунсын.*
*Мендәрләрнең ап-ак төсен,*
*Керләмичә саклагыз.*
*Парлы гомер юлыннан*
*Бәхет белән атлагыз.*

**Ир:**
*Йомшак түшәк өсләрендә*
*Парлы мендәрләр булсын,*
*Гомерегез тигез, матур,*
*Гел шатлыклардан торсын.*

**Икенче хатын:** Бигрәк матур теләкләр әйттегез. Амин, шулай булсын!

**Башкалар да:** Амин! Амин!

**Хуҗабикә:** Менә өмә дә тәмамланды. Тиздән каз бәлеше дә пешеп чыгар. Аңа кадәр уйнап, җырлап-биеп алыйк.

*(Уеннар уйнала, кара-каршы бию башкарыла. Соңыннан өмәдә катнашкан хатын-кызлар, ир-егетләр табын артына утырып, каз бәлеше белән сыйланалар.)*

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

# «АШЫК» УЕНЫ



*Люзия ГАБИТОВА,*
*Чистай районы Татар Сарсазы мәдәният йорты режиссеры*

**Ашык – татар балалары уены. Әлеге уенны уйнар өчен безгә ашыклар кирәк булачак. Нәрсә соң ул ашык? Сарыкларның, кәҗәләрнең үкчә өстендә урнашкан сөяген «ашык» дип йөртәләр.**

***Ашыкканның ашыгы чыккан.***
*(Мәкаль)*











**«Бишташ» уены**

Әлеге уенны 1920-1960 елларда Чистай районы Уракчы авылында гаиләләрдә уйнаганнар. Бу турыда безгә Әлфия әбисе сөйләгәннәрне Айзилә Закирова җиткерде. Гаиләләрдә ашык-сөякләр еллар буе җыелып, буыннан буынга ядкәр итеп тә тапшырылган. Мәсәлән, Айзиләләрдә ул ашыклар 125 данә, әбисенең сандыгында кадерле ядкәр булып саклана.

Әйдәгез, әлеге сөякләр белән, «ашык» уены уйнап алабыз.

Бу уенны урамда да, бүлмәдә дә уйнарга мөмкин.

Ашык өч төрле була. Яны белән баскан ашык «Мулла» дип атала. Чокырлы ягы белән өскә карап торса, «Чек» ашык була. Ә инде чокырлы ягы белән аска караганы «Бек» ашык дип йөртелә.

Бу уенда 2дән алып 6 кешегә кадәр уйный ала. Уенда кеше күбәйгән саен, ашыкның саны да арта гына бара.

Уен түгәрәк өстәл артында, әйтем-санамыштан башлана. Мәсәлән: санамыш иҗекләп әйтелә һәм саналып барыла: «1, 2, 3 у-ры-нын-нан о-чып төш!» Ахыргы иҗек кемдә бетә, уенны шул уйнаучы башлый. Ул өстәлдәге барлык ашыкларны кулына ала, бутый да өстәл өстенә таратып җибәрә. Иң алдан «Мулла» ашыкларны җыеп ала. «Бек» ашыкларны «Бекка» чиртә. Әгәр алар башка ашыкларга бәрелмичә бер-берсенә тисә, 1 ашыкны уйнаучы үзенә ала. Әгәр дә ашыклар чирткәннән соң, бер-берсенә тимәсә, яисә «Бек» «Чекка» тисә, уен 2нче уйнаучыга күчә. Шулай итеп, «Бек» «Бекка», «Чек» «Чекка» чиртелеп, бер-берсенә тисә, ашыклар җыела, уйнаучы ота, тимәсәләр, уен башка уйнаучыга күчә. Икенче уйнаучы да өстәлдәге ашыкларны учына алып бутый да, өскә чөеп, өстәлгә сибә. Уен шулай дәвам итә.

> ***Эт күңеле – бер ашык.***
> *(Мәкаль)*

Өстәлдә бер генә ашык калгач, һәр уйнаучы үзе откан ашыкларны саный. Иң күп ашык җыйган кеше җиңүче була. Җиңүче оттырган уйнаучының очкосына карап, аның маңгаена чиртә. Мәсәлән, җиңүчедә 8 ашык, җиңелүчедә 3 кенә ди. Җиңүче җиңелүченең маңгаена шаяртып, 5 тапкыр чиртә.

## «БИШТАШ» УЕНЫ

Әлеге уенда уйнаучылар балчыктан 5 шар ясыйлар. 4 шар 3х3 зурлыктагы һәм 1 йөртүче – 5х5 зурлыктагы шар булырга тиеш.

Уен 4 турда уза.

### 1нче тур

Шарларның башлангыч урыны: 4 шардан квадрат ясыйлар, шарлар арасындагы ара якынча 15 сантиметр булырга тиеш.

Уен барышы: беренче уенчы 5нче йөртүче шарны алып, өскә ыргыта. Әлеге шар һавадан төшкән арада уйнаучы шул ук кулы белән өстәлдән дә 1 шарны алып өлгерергә тиеш. Уйнаучының кулында 2 шар була. Уен шулай дәвам итеп, уйнаучы калган 3 шарны да шулай алырга тиеш. Әгәр дә барысын да хатасыз эшләсә, ул 2нче турга күчә. Шулай итеп, барлык уйнаучылар 1нче турны үтә. Үтә алмаганнар, 2нче турга күчмиләр.

### 2нче тур

Шарларның башлангыч урыны: 4 шар бер-берсеннән 15-20 сантиметр ераклыкта икешәрләп куела.

Уен барышы: шул ук. Беренче уйнаучы 5нче шарны ала да, өскә ыргыта. Шар һавада булганда, уйнаучы шул ук кулы белән өстәлдән дә янәшә куелган 2 шарны алырга, һавадан төшеп килүче шарны да тотарга тиеш. Уенчының кулында 3 шар була. Калган уйнаучылар да шул тәртиптә уйнап бетерәләр һәм өченче турга күчәләр. Шарларны тота алмаганнар 3нче турга күчми.

### 3нче тур

Шарларның башлангыч урыны: 3 шар бергә.

Уен барышы: барысы да шулай ук кабатлана. Җиңүчеләр 4нче турга күчә, җиңелүчеләр төшеп кала.

4нче турда җиңгәннәр генә катнаша. Алар ике кулларына да икешәр шар алып, өскә чөяләр. Һәм аларны тотарга тиеш булалар. Барлык таләпләрне хатасыз үтәгән уенчы җиңүче була.

***Баласы күп – кашык җыяр, балалары ашык җыяр.***
*(Мәкаль)*





«Чек» ашык



«Бек» ашык



«Мулла» ашык

## «СИКЕРТМЕШ» УЕНЫ

Бу уен да сөякләр белән уйнала. Уйнау тәртибе «Бишташ» уенындагы кебек. Биредә шарлар урынына сөякләрне чөеп уйныйлар. Мәсәлән, араларын 10-15 сантиметр калдырып, 4 сөяктән квадрат ясыйлар. 5нче сөякне өскә чөеп, төшкәнче, шул ук кул белән, өстәлдән бер сөякне алалар. Һәм шулай чиратлашып уйнап, 2нче, 3нче, 4нче турларны да үтеп, җиңүчене билгелиләр.



Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан




**Алия коесы янында узган бәйрәмнән күренеш**

# «Чишмәләребез ни хәлдә?»

***Бөтендөнья татар конгрессы каршында эшләп килүче «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Кадрия Рәес кызы Идрисова Мөслим районында уздырылган күчмә утырышта барыбыз алдында да җитди сорау куйды: «Чишмәләребез ни хәлдә?» Шул уңайдан, быелның август-сентябрь айларында Чистай районында «Чишмәләр» акциясе игълан ителде. Бу акция уңаеннан авылларда күп кенә чишмәләрне барладылар, аларны чистарттылар, халык белән җыелып, булган мәсьәләләрне хәл итү юлларын ачыкладылар.***

Мәсәлән, август аенда Татар Сарсазы авылында «Ага чишмә сулары, бик салкын тамчылары» исемле бәйрәм уздырылды. Бәйрәм Алия коесы янында үтте.

Әлеге коены берничә ел элек авылга Салих әфәнде казыткан. Бу эштә аңа Шыгырданнан Мирсәет Хаҗи улы Күпкынов ярдәм иткән. Җария сәдакасы булырлык кое казыту эшен бергәләп башкаруга аларга Хаҗ кылганда танышу сәбәп булган. Коега хаҗдан алып кайткан зәм-зәм суларын да салганнар. Бәйрәмгә Мирсәет әфәнде үзе дә кунак булып кайткан. Бүгенгесе көнне Алия коесы (Салих әфәнденең кызы исемен йөртә) халыкка хезмәт итә, аның янынан бер дә кеше өзелми.

«Ак калфак» оешмасы ханымнары бәйрәмдә халкыбызның «Яшь киленгә су юлы күрсәтү» һәм «Мунчала чыгару» йолаларын күрсәттеләр.

* * *

Шул ук айда минем туган авылым – Татар Ялтанында да,



Чистай районы «Ак калфак» оешмасы ханымнары

«Таш чишмәдә кунакта» исемле авылдашлар очрашуы узды. Биредә авыл Советы рәисе Равил әфәнде Гарифуллин, Фәдис хәзрәт Гарифуллин, мәдәният хезмәткәрләре Лидия ханым Массарова, Гүзәл ханым Галиева, авыл хуҗалыгы эшмәкәрләре, Чистай җирле татар конгрессы җитәкчесе Фәрит әфәнде Галимов, җирле татар конгрессы каршындагы «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасы вәкилләре, чакырылган кунаклар катнашты.

Чара моңлы азан белән башланып китте. Авылыбызның өлкән кешесе Рафик абый Рәхмәтуллин Таш чишмәнең тарихы белән таныштырды. 2021 елда берничә агай авылдан 5-6 километр ераклыкта гына агып ятучы Усия чишмәсен барып карап кайталар. Аны җиһазлау, халыкка су алуны җайлау хакында уйланалар. Озак та үтми,



Таш чишмә ачылышында

Усия чишмәлегеннән чыгып, мул итеп агучы 5-6 чишмәнең берсенә торба беркетәләр, елга аркылы басма салып, өстәл, мич ясыйлар, сукмакларны тәртипкә китерәләр. Шулай итеп, техникасы булганнар гына түгел, җәяүле авыл халкы да бирегә килеп, тәмле су ала башлый.

Суы искиткеч тәмле булган Таш чишмәнең киләчәген кайгыртып, тирәсе дә төзекләндерелде. Бүгенге көндә чишмә янында бик матур самовар басып тора. Суы җиде торбадан агып чыга. Халыкка басып менәр өчен тимер баскыч куелган. Тәһарәт алып, намаз укырга, чишмә суы белән коенырга теләүчеләр өчен дә җайлы урыннар каралган. Чишмәнең тирә-юненә 150 агач һәм аллы-гөлле чәчәкләр утыртылган.

* * *

Татар Баганалысы авылы да чишмәләргә бай. Авыл халкы өчен иң кадерлеләре Ибраһим бабай белән Балтай чишмәләре. Ибраһим бабай чишмәсенең суы авырулардан дәва булса, Балтай чишмәсе авылның килеп чыгышы белән бәйле.

Татар Баганалысына 1327 елда нигез салына. Хаҗдан кайтып баручы өч Балтач кешесе – Иштирәк, Илмәкәш һәм Әҗем хәл алырга, ял итәргә тукталар. Мондагы челтерәп аккан чишмәләрне, әллә каян үзенә дәшеп торучы куе урманнарны, болыннарны күреп таң калалар. Бераз ял итеп алгач, тәмле чишмә суыннан авыз иткәч, гаиләләрен алып килеп, монда төпләнеп калу уе белән кайтып китәләр. Билгеле инде бу гүзәл урынны югалтмас өчен чишмә янына багана утыртып калдыралар. Менә шуннан Баганалы авылы барлыкка килгән диләр. Балтач якларыннан килеп урнашкан кешеләр хөрмәтенә, әлеге чишмә




**Балтай чишмәсе янында**

«Балтай чишмәсе» дип йөртелә башлый.

Ул көннәр инде шактый артта калган, әмма авыл уртасыннан агучы әлеге чишмә бүген дә үзенең тәмле, мул суы белән авыл халкын сыйлый. Аның суы бер дә бетми, ул ургылып чыгып, үз юлыннан агуын дәвам итә. Татар Баганалысы мәдәният йорты хезмәткәрләре ел саен чишмә буенда бәйрәмнәр оештыралар. Авыл халкы белән бергәләп, чишмә буйларын чистартып торалар.

Һәр бәйрәм Балтай бабай хөрмәтенә дога белән башлана. Халык ул көнне чишмә суыннан куелган самовар чәен эчә-эчә, җырлар җырлап, такмаклар әйтешеп, авылдашлар пешереп килгән тәмле ризыклардан авыз итеп, рәхәтләнеп ял итә.




**Ибраһим бабай чишмәсе**

Чишмә буенда «Карга боткасы», «Яңгыр теләү» йолаларын да үткәрәләр баганалылар. Дөрестән дә чишмә буена төшеп догалар укыгач, бер-берсенә сулар сибешеп, йоласына туры китереп, таудан йомыркалар тәгәрәткәч, тәмле яңгыр боткалары пешереп ашагач, яңгыры да ява башлый.

Әйе, без үзебезнең чишмәләребез янында, гореф-гадәтләребезне дә искә төшереп, киләчәк буынга тапшырып калдырырга тырышабыз. Элеккеге елларда кичке уеннар да чишмә буенда үткән. Без озак еллар чишмәләребезне карап, саклап, төзекләндереп торсак, бер савап булыр иде. Чишмәләр кешеләргә гомер теләп ага, дилэр әби-бабаларыбыз. Без шундый тәмле, чиста, йомшак сулы чишмәләребез булуы белән бик бәхетле. Су яшәү чыганагы да бит әле ул. Чишмәләребезне төзекләндереп, аларга яңа сулыш өрергә генә соңга калмасак иде.







Татар Баганалысы авылында «Яңгыр теләү» йоласыннан күренешләр

*Ерак чишмәләрдән урап-урап,*
*Сулар ташып үскән кызлар без!*
*Көянтәгә элгән чиләкләрдәй,*
*Балкып торыр иде йөзебез...*
*Чайпылдырмый алып кайта идек,*
*Ерак чишмә суын иңнәрдә...*
*Җитезлек һәм өлгерлек буенча*
*Булмагандыр безгә тиңнәр дә!*
*Урам тутырып, без су алып кайттык,*
*Тирә-юньгә сафлык тараттык.*
*Чишмәнең саф суын эчкәнгәме,*
*Тормышта да сафлык яраттык.*
*Кер чайкадык чишмә агышында,*
*Кош сайравын тыңлап, моңнарын.*
*Шуңадырмы, җырлы-моңлы булдык,*
*Җырлап үстек яшьлек җырларын...*
*Көянтәләр асмый хәзер кызлар,*
*Кер чайкаулар калды тарихта...*
*Кош сайравын тыңларга вакыт юк!*
*Кыйммәтләр үзгәрде тормышта.*
*Эчә торган сулар хәзер өйдә!*
*Чишмә буен урау бик сирәк...*
*Ә шулай да, кеше тормышында,*
*Чишмә тавышын ишетү бик кирәк!*

**Рушания ЗАКИРОВА,**
**Чистай җирлеге «Ак калфак»**
**татар хатын-кызлары иҗтимагый**
**оешмасы җитәкчесе,**

**Гөлнара СӨНГАТУЛЛИНА,**
**Татар Баганалысы мәдәният**
**йорты режиссеры**

Автор фоторәсемнәре

# Милли ризык – өстәл күрке

Быелның сентябрь аенда районыбызның иң күркәм залларының берсендә – шәхси эшмәкәр Рифкать Шәфыйковның «Туган авыл» күңел ачу комплексында «Милли аш-су» бәйгесе булып үтте. Бәйге Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов тарафыннан игълан ителгән – 2023 ел – Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына багышланган иде.

Шунысы сөенечле, анда илледән артык туташ һәм ханымнарыбыз катнашты, үзләренең аш-су әзерләү буенча osталыкларын күрсәттеләр. Бәйгегә тәкъдим ителгән ризыклар күп һәм төрле иде. Аларның эшен үзенең 60 ел гомерен районыбызның җәмәгать туклану системасында аш-су әзерләүгә багышлаган легендар пешекче Фәния ханым Мөбарәкова җитәкчелегендәге мәртәбәле жюри бәяләде. Жюри составында беренче номерлы балалар бакчасы мөдире, Бөтендөнья татар конгрессының Теләче бүлеге җитәкчесе Алисә Дәүләтшина һәм районыбызның танылган аш-су остасы, беренче номерлы балалар бакчасы пешекчесе Зөлфия Хәлиуллина бар иде.

Бәйге районыбыз үзешчәннәре җыр-биюләре, уен-көлкеләре белән үрелеп барды. Бәйгедә өстенлек милли ризыкларга бирелде. Кайсы гына милләтне алсак та, ул өстәл күрке булган милли ризыгын күрсәтергә тырышты. Үзебезнекеләрдән өчпочмак, ит һәм борай бәлеше, тутырма, май кабартмасы, кабак бөккәне, мич коймагы, чәк-чәк, кош теле, рус халкының солянкасы, окрошкасы, Пасха куличы, эремчек бөккәне, үзбәкләрнең пылавы, лагманы, мантые, биш бармагы, дәмләмәсе – әнә шундыйлардан.

Камыр ашлары әзерләүдә беренче урынга чәк-чәк пешерү остасы Нәкыя апа Тимергазизова



(Карашырмә) лаек булды. Юка пешереп алып килгән Әлфридә Мәүлина (Шәтке) икенче урынны яуласа, өченче урынга гөбәдия хуҗасы Теләчедән Лилия Рәхмәтуллина чыкты.

Кайнар ризык пешерүдә «иң осталар» дип Равил Насыйбуллин (Иске Җөри, бердәнбер ир-егет катнашучы), Раъногуль Гарипова (Үзәк), Ольга Баканова (Шармыш) табылды.

Иң тәмле кабымлыкларны Кече Мирәтәк авылыннан Сәрия Галимова, Олы Мишәдән Айзилә Мулләхмәтова, Люция һәм Айдар Төхфәтуллиннар әзерләп килгән иде.

Токмач кисү буенча призлы урыннарны Гүзәлия Рәхмәтуллина (Карашырмә), Гөлинә Галимбәкова (Иске Җөри) һәм Гөлсирин Тимербаевалар (Үзәк) бүлеште.

Татар хатын-кызларының аш-суга осталыгы элек-электән хупланган. Шуңа да яшь киленнәрне камыр бастырып, токмач кистереп уңганлыкларын сынаганнар һәм безнең татар кызларын килен итеп төшерү тугандаш халыклар өчен дә зур дәрәҗә саналган. Чара барышында зур тырышлык күрсәткән өстәл хуҗаларының да эше югары бәяләнде. Мисал өчен, Карашырмә авылы уңганнарының (аларның күпчелеге авыл клубы каршында эшләп килүче «Миләшкәй» вокал ансамбле әгъзалары тәшкил итә, җитәкчесе Әкълимә Мәһдиева) өстәле «Иң күркәм өстәл» исеменә лаек булды. Үзәктән килгән Әнисә Миңнебаеваның өстәле «Иң креатив өстәл» дип аталды. Үзәклеләр исә «Иң оригиналь өстәл» хуҗалары буларак танылдылар. Аларның өстәлен икенче төрле «Дуслык өстәле» дип тә атарга мөмкин. Чөнки биредә



таҗик, рус, үзбәк һәм татар халкының камыр ризыклары, кайнар ашлары, кабымлыклары тәкъдим ителгән иде. Район үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре хезмәткәрләре «Дөрес туклану» бренды астында үлән чәйләреннән торган өстәл тәкъдим итте.

Бәйгенең җиңүчеләрен Бөтендөнья татар конгрессының Теләче бүлеге җитәкчесе Алисә Дәүләтшина, район мәдәният бүлеге җитәкчесе Даут Иксанов белән берлектә район башлыгы Нәҗип Хаҗипов бүләкләде. Җиңүчеләргә Мактау грамоталары белән истәлекле бүләкләр тапшырылды. Әмма хикмәт бүләктә түгел, чарада катнашучылар ел буена җитәрлек күңел күтәренкелеге, көч, дәрт алып кайтып киттеләр. Чөнки, алар бергә килеп бер-берсе белән аралаштылар һәм тәҗрибә уртаклаштылар, өйдә чын мәгънәсендә хуҗабикә булырга, йорт җылысын сакларга өйрәнделәр, күркәм, затлы залда һәм мохиттә хозурлану кичерделәр, зәвык тәрбиясе алдылар. Беренче татар ресторанын оештыручы, Ленин һәм Халыклар дуслыгы ордены кавалеры, РСФСРның атказанган сәүдә хезмәткәре, кулинар хезмәтләре өчен алтын медаль белән бүләкләнгән Олы Кибәхуҗа авылыннан Юныс Әхмәтҗанов та безнең якташыбыз. Татар милли ризыклары турындагы тәүге китапны да ул язган. Милли ризыкларыбызны ул күп тапкырлар СССР Халык хуҗалыгы казанышлары ярминкәсендә тәкъдим иткән.

Бәйге уздырылган көнне өстәлләр төрледән-төрле нигъмәтләрдән сыгылып торды. Изге җанлы, ихлас, ягымлы әбиләребез, әниләребез, хәләл җефетләребез һәм кызларыбыз милли ашларыбызның тәмен, үзенчәлеген әлеге көннәргә кадәр саклап калганнар. Республикабызның беренче Президенты Минтимер Шәймиев әйткәнчә, татар милли ашлары – иҗат ул, серле ул, буыннан-буынга күчүче могҗиза ул.

**Фәнил НИГЪМӘТҖАНОВ,**
**Теләче районы**

**Автор фоторәсемнәре**

# Мөнәҗәтләр – җан авазы

*Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,*
*язучы, филология фәннәре докторы, Татарстанның, Россиянең атказанган фән эшлеклесе*




**Россиядә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан нәшер ителгән җыентыкта төрле жанрдагы, шул исәптән дини һәм фәлсәфи, яшәү һәм үлем, сабырлык, ана һәм бала турында мөнәҗәтләр тупланды.**

**Мөнәҗәтләр 2022 елда Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге хезмәткәрләре тарафыннан Әтнә, Буа, Казан, Аксубай, Саба муниципаль районнарына оештырылган фәнни-этнографик экспедицияләр вакытында язып алынды.**

**Җыентык белән кюар-код аша кереп танышырга мөмкин.**

### ФӘЛСӘФИ-ӘХЛАКЫЙ ЭЧТӘЛЕКЛЕ МӨНӘҖӘТЛӘР

Ислам тәгълиматы адәм баласының фани дөньяда кунак кына, вакытлы гына булуын искә төшереп, тормышның кадерен белеп, шәригать кануннарын үтәп, мәңгелектән курыкмыйча көн итү фәлсәфәсен күңелләргә сеңдерә. Фәлсәфи-әхлакый эчтәлекле мөнәҗәтләр инсанны нинди генә авыр хәл-әхвәлләргә юлыкмасын, һәрдаим Аллаһның кодрәтенә, ярлыкавына ышанырга, Коръән сүрәләрен укып, җанын тәрбияләргә, чистарынырга, эчке коллыктан арынырга, дөнья мәшәкатьләре алдында югалып калмаска өйрәтәләр. «Ихласи таянычың Аллаһ һәм ул иңдергән ислам динебез ярдәмендә генә бар авырлыкларны җиңеп, күңел тынычлыгы, җан-тән рәхәте табарсың», – дип язылган «Инандым бер Аллага» мөнәҗәтендә.

*Инандым бер Аллага,*
*Алланың барлыгына,*
*Алланың берлегенә,*
*Бердер илаһым бәнем.*

«Кыз бала», «Аерылгансың балалардан», «Әй, Мостафа Мөхәммәд», «Ялгыз агач», «Торып сахраларга чыгам», «Кайтыр идем туган илгә», «Балакаем, синә сүзем» кебек себер татарлары арасыннан язып алынган мөнәҗәтләрдә аерылу сагышы сабырлыкка, түземле, ярдәмчән булырга өндәүләр, өлкәнне олылап, балаларны дини рухта тәрбияләүгә чакырулар төрле төбәкләрдә яшәүче татарлар өчен уртак фәлсәфи-әхлакый юнәлешне тәшкил итәләр.

Фәлсәфи-әхлакый тармакның асылын тәшкил иткән мөнәҗәтләр шундый нәтиҗә кырына

алып чыгалар: кеше булган кешенең иң зур рухи байлыгы – күңел күрлеге, дип өйрәтә иман. Ә күңел күрлеге – адәм баласын билгеле бер тәрбияви кысаларда тотучы олы көч. «Күңел байлыгы» һәм фәлсәфи-әхлакый компонентлар берсен-берсе тулыландырып киләләр. Фәлсәфә иҗтимагый аңның төп юнәлеше буларак, игътибарын «дөньяга карашны билгели торган белемгә юнәлтә... Фәлсәфә үзенең үзенчәлеген чиксез тирән һәм гомуми, кешелекнең һәр буынына һәм заманына әһәмиятле булган сорауларын да ачыклый». Фәлсәфи эчтәлекле мөнәҗәтләр үлем һәм үлемсезлек, табигать, социаль-сәяси мәсьәләләрнең чишелешен Аллага, Коръән өйрәтмәләренә тугрылык, әхлакый бурычларны дөрес аңлау мәсьәләләрен калкытып куялар. Аллага гыйффәтле мәхәббәттә үзен тапкан суфыйның иң зур максаты – үзенең җаны – рухы белән Аллага «кушылып эрү» һәм шул юл белән бу дөньяда ук мәңгелек рәхәткә ирешү.

*Әгәр алсаң бу җанымны, якты әйлә иманымны,*
*Күтәр житмеш хиҗабыңны, күләем бар дидарыңны.*

*(«Бакый әйлә иманымны»).*

*Тәндә җаным ничә көн миһман икәндер белмәдем.*
*Үтте гомерем, барысы вәйран икәндер, белмәдем.*

*(«Тәндә җаным»).*

«Синең биш асылың» мөнәҗәтендә фәлсәфә әхлак кануннары белән кушылып, камил инсан намус, гакыл, әдәп, күңел, сабыр кебек сыйфатларны үзендә туплаган булырга тиеш. Гыйлемле булу кешене бизәүче сыйфат, оҗмах ишекләре ачылганда терәк таяныч булуына басым ясала. («Гыйлем артыкмы, малмы?» «Гыйлем өстәү фарыздыр», «Дин гыйлеме – татлы җимеш»). Бу мисаллар мөнәҗәтләрнең югары фәлсәфи-әхлакый сыйфатларны үстерү, саклау бурычын үтиләр. Фәлсәфи-әхлакый мөнәҗәтләрнең зур өлешен сабырлык мәүзугы алып тора. Ул күпчелек мөнәҗәтләрнең атамаларына ук чыгарыла. «Ходаем, кыйл сабырлардан», «Кеше хәлен кеше белми», «Сабырлык бир, йә Кәрим», «Сабыр бирсен үзе Аллаһ», «Ходай бирсен әҗерләрен». Соңгы мөнәҗәт сабырлык турында уйланулардан аптырап калган шәхеснең эчке монологы, үз-үзе белән сөйләшүеннән гыйбарәт. Бу мөнәҗәтләрдә еш кулланыла торган әдәби алым. Әүвәл мөнәҗәтче туганнарына мөрәҗәгать итеп, аларны да кисәтә.

*Сабыр итик, сабыр итик, сабыр итми ни хәл итик?*
*Сабыр итмичә туганнар, диваналар булып китмик.*

Үзенең халәтен башкалар белән бүлешкәч, аңа җиңеллек килер дип уйлау да ярдәм итми. Үз хәсрәте үзендә кала. Ул бәргәләнә, уйлана һәм Ходайга мөрәҗәгатендә беркадәр вакытлыча булса да юаныч таба. «Ходаем кыйл сабырлардан!» мөнәҗәтендә әдәбиятта киң таралган капма-каршы кую, ягъни антитеза алымы кулланыла: «сабырларны Ходай сөйгән, сабырсызны ләгыйнь (шайтанның эпитеты) дигән» һәм Ходай аларны сөргән. Мөнәҗәтче кыю, үзенә охшаганнарга кырыс бәя бирүдән дә тайчынып тормый. «Сабырларның «намнәре» сул як тарафыннан килер», ди. Үзен ул «ал як» тарафдарларына кертсә дә, Алладан сабырлык сорый. Күренә ки, мөнәҗәтләр үз холкы, фигыле булган шәхесләрне дә тудыра ала икән. Мөнәҗәтләрнең сюжет-фабула канвалары, композицияләре бертөслерәк күренсәләр дә, сурәтләү чаралары шигырь төзелешләре, мәгънәгә ярашлы рәвештә, шактый бай һәм төрле.

**Ходаем, кыл сабырлык**

*Сабырларны Ходай сөйгән, сабырсызны ләгыйнь дигән,*
*Ләгыйньнәрне Ходай сөргән, Ходаем, кыйл сабырлардан!*
*Сабырларның намәләре килер ал як тарафыннан,*
*Дәки уң як тарафыннан, Ходаем, кыйл сабырлардан!*
*Сабырсызның намәләре килер сул як тарафыннан,*
*Дәки арка тарафыннан, Ходаем, кыйл сабырлардан!*
*Ки тәкъдирдә шулай язган, сабырлык сорыйм Алладан,*
*Сабырдарның эше уңган, Ходаем, кыйл сабырлардан!*

**Ходай бирсен әҗерләрен**

*Сабыр итик, сабыр итик, сабыр итми нихәл итик?*

*Сабыр итмичә, туганнар, диваналар булып китмик.*
*Сабыр итик, сабыр итик, сабыр итми нихәл итик,*
*Сабырсызның эше мөшкел, сабыр итми кая китик?!*
*Бер Ходаем үзе бирсен бу хәсрәтнең әҗерләрен,*
*Бу хәсрәткә сабыр итсәң, нурлы булыр калебләрең.*
*Алай итеп, болай итеп үтә минем гомерләрем,*
*Кайгы-хәсрәтләр белән күтәрелми күңелләрем.*
*Уйлый башым, уйлый башым, уйлама, башым, төрлесен,*
*Төрле уйлар уйлый-уйлый ялгыз гүрләргә керерсең!*

## ТОРМЫШ – КӨНКҮРЕШ, ЯШӘЕШ МӨНӘҖӘТЛӘРЕ

Мөнәҗәтләрнең өченче төркемен тәшкил иткән үрнәкләрендә сүз яшәү мәгънәсе, инсанның тормыштагы урыны, кыйбласы, милли хисләре, туганнары, балалары белән мөнәсәбәтләре, алдарак карап үткән бүлекләр белән уртак сабырлык, гыйлем, үлем һәм үлемсезлек, мәңгелек белән чагыштырганда бер мизгел гомернең кадерен белү хакыйкатьләре турында бара. Бу төркемгә тәкъдим ителгән, дөресрәге, тартылып торган мөнәҗәтләр сан берәмлеге ягыннан иң күпләре булса да, аларның беришесе жанрлык сыйфатлары тарафыннан бәетләргә, озын, моңлы җырларга якын торалар. Үзара тематик керешү сурәтләү чаралары уртаклыгында, хәтта бердәмлегендә дә сизелә. «Читкә киткән кеше мөнәҗәте», «Кайтыр идем туган илгә», «Ата-ана илә тормак дәүләттер», «Ике былбыл», «Сагынуларга юктыр дәва», «Илне сагынып булам дивана», «Ялгыз ана», «Үги бала зары», «Газиз бәбкәм», «Күрәчәгең уйла, мескен», «Куабыз фани дөньяны», «Әйдә, чыгыйк изге юлга», «Белмәдем» кебек күп санлы көйле, милли рухлы мөнәҗәтләр халкыбызның төп өлешенең дингә, яшәеш кануннарына тугрылыклы булып яшәүләренә мисаллар. Бу бүлеккә кергән мөнәҗәтләрнең үзәгендә «гаилә институтын», ягъни ата-ана һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне саклый алмаган кешеләрнең сагыш, юксыну, үкенү кичерешләре. Туганлык хисләрен саклау изге гамәлләрнең үзәгендә торырга тиешлеге искәртелә.

*Берәр кайтып күрерменме печән чапкан тугайларым?*
*Эчем-бәгъремне шул өзә – еглап калды туганнарым.*
*(«Читкә киткән кеше мөнәҗәте»).*

*И кардәшләр, бән сезләрне күрсәм иде.*
*Бән дә сезнең белән йөрсәм иде.*
*(«Кайтыр идем туган илгә»).*

*Кяфер булганнар утта янарлар,*
*Тәмуг эчендә мәңге калырлар.*
*Оҗмахта булыр мөэмин бәндәләр,*
*Дөньяда чакта кыйлса гамәлләр.*
*(«Эчәрбез без әҗәл шәрабен»).*

Тәкъдим ителгән яшәеш, тормыш-көнкүреш турындагы мөнәҗәтчеләрнең төрле һөнәр, белем дәрәҗәләре буенча аерылып торулары да сизелә. Дини, фәлсәфи-әхлакый мөнәҗәтләрнең укымышлы диндар кешеләр, шәкертләр, суфый шагыйрьләр иҗат итсә, ялгызлык моңын, аерылу сагышын, көн итү авырлыгын, якын кешеңне югалту (бу мәүзугъ бәетләр белән уртак) хәсрәтен сурәтләгән тезмәләр күбрәк хатын-кыз күңеленнән өзелеп төшкәннәр. «Аерылдым балалардан», «Бу сагышның бетәсе юктыр», «Күз өстендә кашым идең», «Сагынуларга юктыр дәва», «Анасыннан аерылган кыз зары», «Илне сагынган булам, дивана», «Кавышырга язсын безгә» һәм бередә аталмаган гаҗәп күп санлы мөнәҗәтләрнең үзәгендә ихласлылык, авыр кайгысы, хәсрәте, җан сыкрануы белән бүлешү һәм һәр низагтан арыну җәһәтеннән Аллаһка, динебезгә сыену. «Синең анаң түгелмени?», «Кылыйк тәүбә», «Әҗәлләргә дәвалар юк», «Мәңгелеккә ташлап киттең, балам», «Китик без шулай» мөнәҗәтләрен аналарга илаһи мөнәсәбәт, тормыш авырлыгына бирешмичә, якты гамәлгә чакырулар соңрак чорларда язылган мөнәҗәтләрнең рухын билгелиләр. Икешәр юллы мисраглардан торган «Китик без шулай» мөнәҗәтендә милли мәсьәләләр дә калкытып куела. Халыкны гафләт йокысыннан уятып, алга барырга, максатка барып җитәргә өнди мөнәҗәтче.

*Алданмыйм бер дә юк бар хыялга*
*Көндин көн алга китик без шулай.*

*Милләтне шуңа әйдәп яхшыга,*
*Чыгып яктыга китик без шулай.*

Мөнәҗәтчеләр җәмгыятебездә үсеш авырлыкларын әйтеп, усалланып алудан да, файдасы булсын дип каты-каты чеметеп алудан да тартынып тормыйлар.

**МЕНӘ ШУНДЫЙ ЗАМАН ҖИТӘР**

Ата-анага хөрмәт бетәр, балалардан шәфкать китәр.
Туганнардан рәхим китәр – менә шундый заман җитәр.
Дин гыйлемен уку бетәр, мәсҗедләрне вәйран итәр,
Галимнәрдән чалма китәр – менә шундый заман җитәр.
Ир балада гайрәт бетәр, хатын-кыздан хәят китәр,
Балалардан өмет бетәр – менә шундый заман җитәр.
Биналары биек булыр, эче тулы җиһаз булыр,
Дин дөньясы бозык булыр – менә шундый заман килер.
Галимнәре вәгазь сөйләр, кайберләре гайбәт сөйләр,
Адәм хәвеф белән үлер – менә шундый заман җитәр.
Атасыз бала күбәер, фахишәлек, зина күп булыр,
Мәчетләрдә уен булыр – менә шундый заман җитәр.
Гөнаһны һич тә белмәсләр, биш вакыт намаз кылмаслар,
Заман каһәрен белмәсләр – менә шундый заман җитәр.
Дөньялыкта ямьнәр бетәр, халык китәр уңга-сулга,
Изге гамәл һич кылмаслар, бихисап мал булыр кулда.
Зур-зур биналар салырлар, ашыгып анда барырлар,
Эчендә гауга корырлар – менә шундый заман җитәр.
Ир-хатыннар хәмер эчәр, төрле уеннар корырлар,
Ислам динен онытырлар – менә шундый заман җитәр.
Кяфер исеме киярләр, мине күрсеннәр диярләр,
Тәгамнең барын җыярлар – менә шундый заман җитәр.
Базарлар да очсызланыр, яңгырлар да сирәк явыр,
Хәрәм ашаулар күп булыр – менә шундый заман җитәр.
Халык әһле көчсез булыр, хәйләкәр адәм күп булыр,
Дин иясе гаҗиз булыр – менә шундый заман җитәр.
Балалары түрә булыр, хатыннары солтан булыр,
Һәм ирләре коллар булыр – менә шундый заман җитәр.

Әлбәттә, төрле буын, төбәк галимнәребезнең эзләнүләренә таянып иҗат ителгән әлеге төркемләү дә бәхәс уятырга мөмкин. Уртак байлыгыбызны бәяләүдә фикер төрлелеге булуы табигый хәл – хакыйкать, дөреслек үзара аралашу, фикерләшү барышында гына табыла ала. Шунысы бәхәссез: күңелнең биек һәм бөек киштәсендә урын алып торган мөнәҗәт жанрының үткәне һәм бүгенгесе, милли аңыбызның, телебезнең җан авазы, шигъри юлдашы үткәнебез мирасы гына түгел, ә хәзер дә безнең даими таянычыбыз, киләчәк тормышыбызның якты һәм сүнмәс-сүрелмәс маягы. Бу рухи кыйммәтләр безнең мәдәниятнең аерылгысыз өлешен тәшкил итәләр һәм халкыбыз аны иң фаҗигале елларда да күңелендә, йөрәгендә саклап яңа буыннарга тапшыра килде.

**Кулланылган әдәбият:**
Бакиров М.Х. Татар фольклоры. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 299-348.
Хан кызы / Төз. Җ. Зәйнуллин. – Казан: Мәгариф, 1994. – 95 б.
Садыкова А.Х. Татарские мунажаты в типологическом освещении. – Казань, Тат. кн. издат., 1999.
Нигъмәтҗанов М. Татар халык җырлары. – Казан, 1976. – Б. 25.
Сибгатуллина Ә. Татар әдәбиятында суфыйчылык. – Казан, 2000. – Б. 334.
Хөснуллин К.М. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр. – Казан: Раннур. – 724 б.

# Түбәнәк талантлары

**«Рухият» мандолиначылар ансамбле Башкортстан Республикасы Туймазы районы Түбәнәк мәдәният йорты каршында 2015 елдан эшләп килә. Биредә 9-16 яшьлек балалар шөгыльләнә.**

**Ансамбль репертуарында «Туган тел», «Сарман», «Суда, суда», «Ай, былбылым» кебек татар, «Сыңрау Торна», «Шәл бәйләдем», «Гөлнәзирә», «Карабай» кебек башкорт көйләре дә бар.**

**«Рухият»ләрнең уңышлары да шактый:**

- 2019 елда Казанда үткән «Түгәрәк уен» фольклор фестивалендә III дәрәҗә лауреат исеменә лаек булганнар;
- 2020 елда ТАССРның 100 еллыгында катнашканнар;
- 2022 елда Казанда үткән «Этномириада» Халыкара конкурс-фестивалендә I дәрәҗә лауреат булганнар;
- 2023 елда Башкорстанда уздырылган республика бәйгесендә ике тапкыр лауреат исемен алганнар.






*– Ансамбльгә бик талантлы, тырыш балалар йөри. Алар безнең горурлыгыбыз. Мандолиналарны район күләмендә үткәрелгән «Иң әйбәт мәдәният йорты» бәйгесендә җиңгән акчага сатып алдык. Татар милли киемнәрен авылдашыбыз, эшмәкәр Фәнир Галимов ярдәмендә тектердек. Башкорт милли киемнәрен Район мәдәният йортыннан алып торабыз»,* – ди Төмәнәк авылы мәдәният йорты һәм «Рухият» мандолиначылар ансамбле җитәкчесе Раушания Зарипова.





Чистай районы Гаделша мәктәбе укучылары укытучылары Ирина Хәмидуллина белән



# Ява карлар

Наилә Яхина көе һәм сүзләре




*Калаларны, урманнарны,*
*Бик-бик ерак авылларны,*
*Карлы буран каплап узган –*
*Яшерепме салкыннардан...*

***Кушымта:***
*Ява карлар, ява карлар,*
*Ап-ак булган бар дөньялар.*
*Тоташ булган, кушылганнар*
*Ак тауларга урман-кырлар.*

*Качкан күлләр, елгалары,*
*Өнсез калган тугайлары.*
*Ишетелми кошлары да –*
*Адаштырган бураннармы?..*

***Кушымта.***

# БОРЧАК ЧУМАРЫ

Чумар – кайнап торган итле шулпага яисә сөткә салып пешерелә торган вак камыр кисәкләре. Аның диалектларда цумар, чумара кебек төрле атамалары да очрый. Чумар күрше халыклар телендә, мәсәлән, башкортларда – сумар, удмуртларда – чумар, мариларда – чомар, мордваларда цемара – пилмән дип тә атала.

Халык арасында «килен чумары» – яшь килен пешергән чумар аеруча данлыклы. Килен чумарын ашарга килгәндә һәркем үзе белән бүләк алып килә һәм киленгә бүләк итеп бирә. Русларда туйның соңгы көнендә пешерелә торган аш «прашшай чумары» дип йөртелә.

Без бүген чумарны итле шулпада пешербез.

«Татарханә» проектының «Татар табыны» рубрикасыннан. Рубриканы «Тәмле булсын» рестораннар челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, танылган аш-су остасы **Резидә Кыям кызы ХӨСӘЕНОВА** алып бара.







## КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

**Шулпа өчен:**
300 грамм сөякле сыер ите,
2 литр су,
2 данә бәрәңге,
1 данә кишер,
2 данә суган,
тәменчә тоз.

**Камыр өчен:**
1,5 стакан борчак оны,
2 аш кашыгы шулпа,
2 данә йомырка,
бер чеметем тоз.



1 Камыр басар алдыннан, бүлмә температурасындагы сыер итен салкын суда юып, салкын суга салып, кайнатырга куябыз. Суы кайнап чыккач, өстенә чыккан күбекне җыеп алып, түменчә тоз салып, сүрән утта 1-1,5 сәгать кайнатабыз. Ите пешкәч, суытырга алып куябыз.





2 Шулпаны сөзеп яңадан кайнатырга куябыз һәм аңа чистарткан бәрәңгене шакмаклап турап, кишерне кыргычтан уып салабыз. Суганны вак кына турап, кыздырабыз.



3 Шулпадагы яшелчәләр пешкән арада борчак оныннан камыр басабыз. Савытка 2 йомырка сытып, бер чеметем тоз салып, 1-2 аш кашыгы суынган шулпа өстәп, борчак онын кушып, камыр басабыз.



**4** Яшелчәләре пешкән, сүрән утта кайнап утырган шулпага, камыр сыек килеп чыкса, кечкенә сөзгеч аша агызабыз яисә каты камырны өзгәләп салабыз.



**5** Камыр пешкән арада чумар өстенә кыздырылган суганны салабыз. Яшел суган, әнис турыйбыз. 5-7 минут узганнан соң, чумар өскә күтәрелгәч, шулпаны уттан алабыз.




**6** Борчак чумарын аш тәлинкәсенә, киселгән ит кисәге өстенә салып, табынга чыгарабыз. Яшел тәмләткечләр белән бизәргә дә мөмкин.

АШЛАРЫГЫЗ ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Бергәләп бизибез!



# Истәлекле даталар
## 2024

### ГЫЙНВАР

**1 гыйнвар**

Композитор, беренче татар балеты «Шүрәле»нең авторы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәрит Заһидулла улы Яруллинның тууына 110 ел (1914-1943)

**5 гыйнвар**

Балет буенча репетитор, Татарстан Республикасының атказанган артисты Рәйсә Ималетдин кызы Хәсәновага 70 яшь (1954)

**7 (19) гыйнвар**

Композитор, скрипкачы, педагог, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, беренче татар операсы «Сания» авторларының берсе Василий Иванович Виноградовның тууына 150 ел (1874-1948)

**7 гыйнвар**

График, рәссам, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премиясе лауреаты, Россия сәнгать академиясенең заманча сәнгать өлкәсендәге Н.И. Фешин премиясе лауреаты Ирина Валериевна Антоновага 60 яшь (1964)

**12 гыйнвар**

Сәнгать белгече, сәнгать белеме кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.И. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Ольга Львовна Улемновага 60 яшь (1964)

**25 гыйнвар**

Сынчы, график, бизәүче, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Фәһим Нуретдин улы Фәсхетдиновның тууына 80 ел (1944-2015)

### ФЕВРАЛЬ

**2 февраль**

Җырчы, Татарстан АССРның атказанган артисты Руслан Габдулла улы Дәминовка 75 яшь (1949)

**10 февраль**

Актёр, режиссёр, педагог, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәфкать Әхмәтҗан улы Бикчәнтәевнең тууына 100 ел (1924-1975)

**10 февраль**

Татарстан Республикасының халык рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Рәшит Хәмис улы Газиевкә 70 яшь (1954-2021)

**11 февраль**

Архитектор-реставратор, Татарстан Республикасының атказанган архитекторы Фәридә Мөхәммәт кызы Зәбированың тууына 70 ел (1954-2021)

**14 февраль**

Рәссам Илгизәр Исмәгыйль улы Еникиевкә 80 яшь (1944)

**14 февраль**

Язучы, публицист Нияз Рәшит улы Акмалның (Акмалов) тууына 70 ел (1954-2007)

**23 февраль**

Шагыйрь һәм журналист, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Госман Мохтәсар улы Садәнең (Зәйнетдинев) тууына 75 ел (1949-2014)

**24 февраль**

Актриса, Татарстан АССРның һәм Россия Федерациясенең халык артисты, Ро ссиянең К.С. Станиславский исемендәге, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Алсу Әскәр кызы Гайнуллинага 70 яшь (1954)

**25 февраль**

Рәссам, театр рәссамы, Татарстан АССРның халык, РСФСРның атказанган рәссамы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әнәс Ибраһим улы Тумашевның тууына 100 ел (1924-2010)

### МАРТ

**1 март**

Рәссам, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының халык рәссамы Мәдияр Шәрип улы Хаҗиевкә 75 яшь (1949)

**18 март**

Сәнгать тарихчысы, сәнгать белеме кандидаты Гүзәл Ринат кызы Фәйзрахмановага 50 яшь (1974)

**25 март**

Җырчы, Татарстан Республикасының халык артисты Мөнир Әхәт улы Якуповка 75 яшь (1949)

**28 март**

Актёр, режиссёр, Г. Кариев исемендәге Татар яшьләр театрының баш режиссёры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ринат Мирзахәсән улы Әюповка 60 яшь (1964)

**30 март**

Рәссам, монументалист, Татарстан Республикасының халык рәссамы, Россия Федерациясенең атказанган рәссамы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рөстәм Әхмәт улы Килдебәковка 90 яшь (1934-2023)

https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды



**Кадерле укучыларыбыз!**
2024 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 283 сум 39 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 566 сум 78 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!